ДҮШӘМБЕ
15 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 87 (5887)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: *Казан, Матбугат йорты.* ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮНЕ БОЛЬШЕВИСТИК ОЕШКАНЛЫК БЕЛӘН ҮТКӘРИК!

Кадрларыбызның техник һәм гомуми белемнәрен тагын да күтәрик

Социалистик индустриябезнең бай һәм катлаулы техникасының большевикларча үзләштергән кадрлар, техниканың барлык нечкәлекләрен иярли ала торган кадрлар барсын да хәл итәләр. Илебезнең киләчәктә дә чәчәк атуы, экономик һәм оборона куәтенең тагын да ныгуы башлыча шуларга бәйләнгән.

Безнең кадрлар, партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең теләсә нинди заданиесен үтәргә хәзер торган партияле һәм партиясез большевикларыбыз бөек Ленин—Сталин партиясенең, иптәш Сталинның аталарча тирән кайгыртучанлыгы белән чолганып алынганнар. Моны без һәр көн, һәр сәгат саен хис итәбез. Иҗад итү өчен, үзеңнең политик, техник һәм гомуми белемеңне күтәрү өчен бездә бөтен шартлар, бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Ленин—Сталин партиясе эшенә, коммунизм эшенә ахрынача бирелгән, социализм иле шартларында тәрбияләнгән гүзәл кадрларыбыз кыю рәвештә җитәкче эшләргә күтәреләләр.

Татарстан республикасы предприятиеләрендә генә дә соңгы елларда меңнәрчә стахановчылар цех һәм участкы начальниклары итеп, завод, фабрика һәм комбинат директорлары итеп күтәрелделәр. Элек гади эшче, хәзер Вахитов исемендәге Жиркомбинат директоры Логинов, „Спартак" комбинаты директоры Ситников, Ленин исемендәге Җитен комбинаты директоры урынбасары, СССР Верховный Советы депутаты Төхфәтуллина, Казан тимер юлында Әгерҗе бүлеге начальнигы ярдәмчесе орденлы Исхакова кебек практик эштә үскән йөзләрчә иптәшләр әнә шул алдынгыларның вәкилләре. Аларның исемен бөтен республикабыз белә. Алар Сталин Конституциясе канаты астында үсәләр, югары күтәреләләр. Большевистик җитәкчелек стилен кыю рәвештә үзләштерәләр, үзләренең техник һәм гомуми белемнәрен күтәрү өстендә тырышып эшлиләр.

Бу кадрларның техник һәм гомуми белемнәрен туктаусыз күтәрә бару, аларны чын-чынлап бүгенге көн таләпләренә, Сталин эпохасы таләпләренә җавап бирерлек җитәкчеләр итеп тәрбияләү—зур әһәмиятле һәм мактаулы бурыч. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның бу турыдагы күрсәтмәләрен бер генә минутка да хәтердән чыгармаска кирәк: „Акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы капма-каршылыкны бетерүгә эшчеләр сыйныфының культура-техник дәрәҗәсен инженер-техниклык хезмәте работниклары дәрәҗәсенә күтәрү базасында гына ирешергә мөмкин... Эшчеләр сыйныфының культура-техник ягыннан шундый күтәрелеше генә акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы капма-каршылыкның нигезләрен җимерә ала, социализмнан коммунизмга күчә башлау өчен кирәк булган югары хезмәт җитештерүчәнлеген һәм куллану әйберләренең муллыгын бары тик ул гына тәэмин итә ала..."

Юлбашчыбызның бу сугышчан күрсәтмәләрен тормышка ашыру өлкәсендә республикабызда зур эшләр башкарыла. Укуга, фәнне, техниканы үзләштерүгә булган омтылыш елдан-ел, көннән-көн көчәя. Мәсәлән, язу машиналары заводында хәзер йөзләрчә кешеләр социалистик хезмәт мастерлары мәктәбендә, инженер-техник работниклар семинарында һәм Наркомат янында оештырылган хуҗалык работниклары институтында укыйлар, урта һәм югары белем алалар. Кадрларның квалификацияләрен һәм белемнәрен күтәрү эшенә һәр ел саен йөз меңнәрчә сум акча тотыла.

Мондый яхшы эш үрнәген җиңел промышленность предприятиеләре буенча да күп кенә китерергә мөмкин. Кадрлар белән эшләү, аларны тәрбияләү, эшкә өйрәтү дәүләт планнарын үтәүгә көчле этәргеч ясый. Мәсәлән, күн-галантерея фабрикасы берничә еллар буена артта калып килде. Чөнки монда эшчеләрнең квалификацияләре түбән, яңа эшчеләрне эшкә өйрәтү чаралары йомшак оештырылган иде. Бу кимчелекләрне бетерү фабриканың йөзен тамырыннан үзгәртте. Фабрика планын арттырып үти башлады. Брак кискен рәвештә кимеде. Элек нормасын үти алмаган, күптән түгел генә колхоздан килгән иптәш Неклюдова кебек күп кенә иптәшләр нормаларын 150—200 процентка үти башладылар. Хәзер Неклюдова, Низаметтинова, Байбурина иптәшләр мастер дәрәҗәсенә кадәр күтәрелделәр һәм үз эшләрен зур осталык белән башкаралар.

Шулай да, кадрларны тәрбияләү өлкәсендәге бу беренче казанышлар гына безгә тынычлану хокукын бирми әле. Дөресен әйтергә кирәк, кадрларга җансыз караш фактларын урыннарда байтак очратырга мөмкин. Мәсәлән, киез-итек фетр фабрикасында җитәкче эшкә күтәрелгән кадрларның техник һәм гомуми белемнәрен күтәрү эшенә җитәрлек игтибар итмиләр. Байтак кына цех начальниклары һәм мастерлар бер кайда да укымыйлар. Яки менә Зеленодольски шәһәрендәге 3 нче номерлы фанер заводын алыйк. Заводның утиль цехында бер ел эчендә 4 начальник алмашынган. Узган елның көзендә цех начальнигы итеп күтәрелгән стахановчы иптәш Миңлегалиев 5—6 ай эшләгәннән соң, „эшне оештыра алмый" дигән сылтау белән бүлек мастерлыгына төшерелә. Ә аңа ярдәм итү турында һич кем кайгыртмый. Мондый фактлар башка кайбер предприятиеләрдә дә бар.

Кадрларны тәрбияләү эше Казан тимер юлында бигрәк тә начар тора. Яшь кадрларны көндәлек игтибар белән чолгап алу урнына, шелтәләр яудыру юлына басканнар. Әгерҗе һәм Юдино бүлекләрендә җитәкче эшкә яңа гына күтәрелгән иптәшләрнең күпчелегенә служба һәм бүлек начальниклары тарафыннан шелтә иглан ителгән.

Кадрларны күтәрү белән генә тынычланмаска, аларның техник һәм гомуми белемнәрен күтәрү буенча, практик эштә булышлык итү буенча көндәлек кайгыртучанлык булдырырга кирәк. Партиябез һәм хөкүмәтебез моны бездән бөтен кискенлеге белән таләп итәләр. Кадрлар турында Сталинча кайгыртучанлык күрсәтергә, аларга һәр яклап булышлык итәргә—бурыч әнә шундый.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Грузия ССР ның Багдади авылының исемен Маяковский авылы дип һәм Багдади районын Маяковский районы дип үзгәртү турында

Грузия ССР ның Багдади районы колхозчыларының һәм хезмәт ияләренең үтенечен канәгатьләндерергә һәм В. В. МАЯКОВСКИЙ ның үлүенә 10 ел тулу уңае белән Маяковскийның туган авылы—Багдади авылының исемен—Маяковский авылы дип һәм Багдади районын—Маяковский районы дип үзгәртергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.
Москва, Кремль. 13 апрель, 1940 ел.

ТАСС НЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

Англиянең „Дейли телеграф энд Морнинг пост" газетасы һәм Литваның „Лиетувос айдас" газетасы Германия гаскәрләре Нарвикка Мурманскидан китерелгәннәр һәм алар аңа кадәр дә шунда булганнар дигән хәбәрләр басып чыгарганнар.

„Дейли телеграф энд Морнинг пост"ның һәм „Лиетувос айдас" ның бу хәбәрләренең һич тә дөрес түгеллеген һәм провокацион уйдырма икәнлекләрен белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

ССР СОЮЗЫ БЕЛӘН ЛИТВАНЫҢ ҮЗӘК КАТНАШ ЧИК БУЕ КОМИССИЯСЕНЕҢ БЕЛДЕРҮЕ

Совет—Литва дәүләт чиген демаркацияләү буенча 1940 нчы елның мартында кыр эшләре тәмам булды. Чикнең гомуми озынлыгы 370 километр. Барлыгы 609 чик буе билгесе (1.218 багана) куелды.

Яңа чикне топографиягә төшереп алу нигезендә тәмам булды.

КЫР ЭШЛӘРЕ УҢЫШЛЫ БАРА

ОКТЯБРЬ—НОРЛАТ, 14 апрель. **(Телефон буенча).** Октябрь районының „Ерепкино", „Виктория", „Большевик" һәм башка күп кенә колхозларында кыр эшләре зур күтәренкелек белән башланды. 13 нче апрельдә „Ерепкино" колхозында 37 һәм „Виктория" колхозында 18 гектар мәйданда сөрү үткәрелде. „Ерепкино" колхозы членнарыннан Наталия Еремеева, Ольга Ильина, Татьяна Дементьева һәм Ф. Ухванова иптәшләр язгы сөрүдә көнлек нормны беренче көнне үк 120 процентка кадәр арттырып үтәүгә ирештеләр.

М. Вафин.
ВКП(б) райкомы секретаре.

ӨЛГЕРГӘН УЧАСТКЫЛАРДА

БУА, 14 апрель. **(Телефон буенча).** Язгы кыр эшләренә керешү өчен басулар өлгереп килә. Кичә, 13 нче апрельдә „Трудовик" колхозында өлгергән участкыларда язгы сөрү эшенә керештеләр.

Колхозлар бәртекле ашлык орлыклары белән тәэмин ителделәр. Киндер һәм беркадәр җитешмәгән бәрәңгене колхозара социалистик ярдәм тәртибендә табу чаралары күрелде. Практика, колхозчыларның бу чараны бик яхшы каршы алуларын күрсәтте. Тик алар арасында масса-аңлату эшләрен генә оештырырга кирәк. „Марс", „Маяк", „Красный Партизан", „Потемкин", „Коминтерн" һәм башка күп кенә колхозларда солы һәм вика орлыкларын [illegible].

Хатямов.
Район җир бүлеге мөдире.

13 нче апрельдә, төштән соң Чистай районының „Мәгариф", „Смена" һәм „Доброволец" колхозларында язгы кыр эшләре башланды. „Смена" колхозында шул көнне, өлгергән участкыларда сайлап сөрү үткәрделәр. „Доброволец" колхозында яшелчә утырту өчен 7 гектар чирәм сөрделәр.

Иртә культураларны чәчү башланды

Азнакай районының күп кенә колхозларында иртә культураларны чәчү башланды. „Кичү" колхозы 60 гектар солы һәм борчак, Энгельс исемендәге колхоз 41 гектар солы чәчтеләр инде.

Районда кыр эшләре башланганнан алып хәзергә кадәр 623 гектар мәйданда язгы сөрү үткәрелде. 1.050 гектар мәйданда культивация ясалды һәм 4.400 гектар мәйданда тырмалау үткәрелде. 276 гектар мәйданда чәчелде.

Колхоз басуларында хәзерге көндә 40 трактор эшли.

Яңа Писмән районының 7 нче апрельдә кыр эшләренә керешкән „Үзәк" колхозы 13 нче апрельгә 218 гектар мәйданда язгы сөрү һәм 208 гектар мәйданда тунга сөрелгән җирларне тырмалау үткәрде. „Иркен" колхозында да кыр эшләре көннән-көн кыза. Бу колхоз 13 нче апрельдә борчак чәчү эшенә кереште. Районда колхозларның 22 сендә кыр эшләре бара. (ТатТАСС).

КЛЕВЕР ЧӘЧӘЛӘР

КУКМАРА, 14 апрель. **(Телефон буенча).** Районның „Труженик" колхозы 12 нче апрельдә язгы кыр эшләренә кереште. Беренче булып 30 гектар клевер чәчте. „Күргәзмә", „Беренче Май" һәм „Интурист" колхозлары да кыр эшләренә керештеләр.

Хисамов.

КОЛХОЗЧЫЛАР ЧӘЧҮЛЕК ОРЛЫК БЕЛӘН ЯРДӘМ ИТӘЛӘР

Борнаш авылының Ленин исемендәге колхозында (Апас районы) чәчүлек орлыклар җитешми. Колхозчыларның гомуми җыелышы колхозга чәчүлек орлык белән ярдәм итү турында карар чыгарды. Шул ук җыелышта Вәлиев, Мөхәмәтшин һәм Гыймадеев иптәшләр үзләренең запас фондларыннан колхозга чәчүлек орлык бирергә теләкләрен белдерделәр. Иптәш Гыймадеев икенче көнне үк колхозга бурычка 8 центнер орлык бирде.

Х. Хәйруллин.
Борнаш авыл советы председателе.

КЫР ЭШЛӘРЕ БАШЛАНДЫ, Ә ТРАКТОРЛАР ӘЗЕР ТҮГЕЛ

Кызыл Армия районының „Динамо", „Комбайн", „Активист", „Марс" һәм Карл Маркс исемендәге колхозларында язгы кыр эшләре башланды. „Активист", „Динамо" һәм Нәриман исемендәге колхозларда тракторлар да эшкә керештеләр. Ләкин Тат. Ялтан һәм Каргалы МТС ларының язгы чәчүне хәзерлексез каршы алуларын әйтергә кирәк.

Бу ике МТС ның икесендә дә тракторларга ремонт ясау һаман да төгәлләнгәне юк. Тат. Ялтан МТС ында 12 трактор, Каргалы МТС ында 11 трактор һаман да ремонтта әле. „Беренче Май" колхозында икенче тәүлек инде бер тракторны ходка җибәрә алмыйлар. Тикшергәннән соң бу тракторга ремонтның начар ясалганлыгы билгеле булды.

Иясезлек нәтиҗәсе

Буденный районының күп кенә колхозларында атларны язгы чәчүгә хәзерлек эшендә бик күп кимчелекләр бар. Киров исемендәге колхозда 42 атның бөтенесе дә уртачадан түбән көрлектә. 17 атның җилкәләре күздән бирле инде бозык. Колхозның ветсанитары Кириллов ат абзарларына кереп тә караганы юк. „Красное Новоселки" колхозында да 40 атның бөтенесе дә чиктән тыш ябыклар, 11 енең җилкәләре бозык. „Правда", „Гигант № 1", Сталин исемендәге колхозда һәм башка күп кенә колхозларда да атларның хәле шундый. Бу колхозларда атларны тәрбия итүгә җавапсызлык, иясезлек хөкем сөрә. Атлар чистартылмый һәм абзардагы тирес җыештырылмый.

Февраль аенда атларның торышына тикшерү үткәрелгән иде һәм атларны тәрбия итү эшен яхшырту турында район җир бүлегенә тиешле күрсәтмәләр бирелгән иде. Район җир бүлеге бу мәсьәлә белән шөгылләнмәде.

(ТатТАСС).

Звенолар бар, ә кешеләре юк

Татарстанның кайбер районнарында язгы чәчү башланды. Ә Арча районының „Кызыл сабан" колхозы чәчүгә хәзер түгел.

Чәчү орлыклары күптән инде хәзерләнгән булырга тиеш иде. Ләкин тары орлыгы лабораториядә яраксыз дип табыла. Силос культуралары чәчү өчен орлыклар бөтенләй юк.

Атларны тәрбияләү эшенә игтибарсыз карау нәтиҗәсендә аларның байтак өлеше түбән көрлектә. Колхоз шушы көннәр эчендә басуга чыгарга тиеш. Ә арбаларның зур күпчелегенә ремонт ясалмаган. Чөнки такта яручылар, такта яру өчен җылы урын юк, дигән сылтау белән көннәр җылынганны көткәннәр. Хәзер дип исәпләнгән арбаларның да яки такталары юк, я булмаса, тугымнары ватык.

Колхозчылар чәчү өстендә үзләренең кайда һәм нәрсә эшләргә тиешлекләрен шушы көнгә кадәр белмиләр. Чөнки даими звенолар кәгазьдә генә төзелгәннәр. Аларга кешеләр беркетелмәгән.

Колхоз, бу җитешсезлекләрне ашыгыч рәвештә бетереп, язгы чәчүне кыска сроклар эчендә төгәлләүне тәэмин итәргә тиеш.

Нәби.



Щербиновская районының (Краснодар крае) партиянең XVII нче съезды исемендәге колхозында. Рәсемдә: Яңа Щербиновский МТС ы тракторчысы, 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуга кандидат иптәш М. Н. Фисун чәчү вактында.

Л. Кадимов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СТАЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ КОЛХОЗ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕР ТҮГЕЛ

Арчаның җитәкче район оешмалары Сталин исемендәге колхозны алдынгы колхозларның берсе дип исәплиләр. Чыннан да, аның уңышлы яклары аз түгел. Ул бай гына колхоз. Машиналары, җире күп. Ә менә язгы чәчүгә хәзерлек эшендә аның зур кимчелекләре бар.

Атларны алыйк. Аларның байтак өлеше түбән көрлектә. Азык җитәрлек түгелме? Юк, алай түгел. Азык бар. Моның сәбәбе—атларны норма белән, үлчәп ашатуга бригадирларның да, ат караучыларның да игтибар бирмәүләрендә. Атлардан файдалануда иясезлек хөкем сөрә. Шуның нәтиҗәсе буларак, 4 нче бригадада 3 атның җилкәсен ыңгырчак баскан. 1 нче бригаданың бригадиры Закиров чәчү машинасына җигеләчәк бер ат белән урманга барып, аны 22 сәгать тоташтан ач тоткан. Нәтиҗәдә бу ат чиктән тыш өшәнгән.

Чәчүгә чыгарга бик санаулы көннәр калды. Ә бу колхозда әле чәчү орлыгы да тулысынча хәзерләнмәгән. Тагын 600 центнер бәрәңге орлыгы кирәк. Амбарда яхшылап сакланмау нәтиҗәсендә тары орлыгы чәчәргә яраксыз хәлгә килгән. Карабодай орлыгының да тишелеп чыгышы бары 89 процент. Тагын 12 центнер клевер, 320 килограмм киндер, 1 гектар өчен суган орлыгы кирәк. Бу орлыкларны табу буенча колхоз правлениесе тарафыннан хәзергә кадәр конкрет бер эш тә эшләнмәгән.

Агротехника чараларын үткәрү эшендә дә зур кимчелекләр бар. Басуга чыгарылган тирес агротехника кагыйдәләре буенча өеп куелмаган. Болындагы торф та чәчеләп ята. Көл 360 центнер урнына бары 56 центнер, фикали 100 тонна урнына бары 185 центнер хәзерләнгән.

Колхозның басулары шактый ерак. Кыр станнары кирәк. Ләкин кыр станнарына ремонт ясау, тракторчылар өчен вагоннар хәзерләү һәм аларны кирәкле җиһазлар белән җиһазлау турында колхоз правлениесе уйлап та карамаган.

Болар барсы да Сталин исемендәге колхозның язга хәзерлек турында алдан кайгыртмаган булуын күрсәтәләр.

Дөрес, бригадаларда даими звенолар оештырылган. Ләкин звено членнары шушы көнгә кадәр үзләренең кайда һәм нәрсә эшләячәкләрен белмиләр. Бригадалар арасында социалистик ярыш договорлары төзелгән булса да, аларның үтәлеше бер генә тапкыр да тикшерелмәгән. Звенолар арасында ярыш бөтенләй юк.

Үткән елны 82 кешенең хезмәт минимумын үтәмәве хезмәт дисциплинасының түбән булганлыгын күрсәтә торган факт. Колхоз правлениесе, колхозчыларның эшкә чыкмау сәбәпләрен тирәнтен өйрәнеп, колхозчыларны тәрбияләү урнына, аларның кайберләрен механик рәвештә колхоздан чыгару белән чикләнгән. Хәтта колхозчыларны күз артында чыгаруга кадәр барып җитү фактлары да булган. Колхоз правлениесе бу әһәмиятле мәсьәлә белән әле дә җитәрлек шөгылләнми.

Арча районы оешмалары Сталин исемендәге колхозга нык игтибар бирергә һәм аның язгы чәчүне уңышлы рәвештә үткәрүе тәэмин ителергә тиеш.

Н. Мансуров.

МТС ларда тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 10 нчы апреленә
(Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Төньяк районнар:		Чистай	100,0	*Көнбатыш районнар:*	
Нөркәй	100,0	Куйбышев	98,0	Кама Тамагы	100,0
Теләче	100,0	Зур Поляна	97,6	Юртыш	100,0
Маткавыш	100,0	Мөслим (Чистай)	95,8	Дәүләки	100,0
Актаныш	100,0	Ст. Тимошкино	95,1	Чүпрәле	100,0
Мөслим	100,0	Каргалы	94,6	Ишеево	100,0
Янил	100,0	Алексеевский	93,2	Майдан	100,0
Алга	100,0	Базарлы Матак	92,6	Норлат	97,8
Кадрәк	100,0	Кузнечиха	90,7	Тархан	97,7
Тирсә	100,0	Кошкинский	90,0	Буденный	96,4
Т. Тамак	100,0	Әлки	86,0	Тәтеш	96,3
Минзәлә	100,0	Трехозерский	86,0	Мөрәле	95,9
Азин	100,0	Тельман	84,0	Олы Кариле	95,8
Балтач	100,0	Тат. Ялтан	83,3	Макыл	94,1
Чаллы	100,0	Чиябаш	74,5	Чокалы	92,7
Исәнбай	100,0	Яңа Чишмә	73,3	Биектау	92,5
Кукмара	100,0	Ромадан	65,9	Мәлки	91,7
Тәкәнеш	100,0	Барлыгы	91,6	Питрәч	91,1
Морт	97,9	*Көньяк-көнчыгыш районнар:*		Константиновский	90,6
Бондюг	97,7	Тымытык	100,0	Тат. Ходяш	89,4
Алабуга	96,4	Әлмәт	100,0	Столбище	89,1
Калинин	90,7	Беренче Май	100,0	Әхмәмәт	88,6
Әтнә	90,0	Сарман	100,0	Буа	88,4
Арча	89,7	Чалпы	100,0	Әлши	88,1
Кызыл Йолдыз	89,1	Кичү	100,0	Дөбъяз	87,0
Саба	88,6	Кәкре Елга	100,0	Юдино	80,9
Мамадыш	87,0	Акташ	100,0	Чүрибураш	79,1
Балык Бистәсе	86,0	Ютазы	100,0	Зөя	71,8
Кызыл Юл	84,7	Шөгер	98,0	Рождественский	62,3
Димитровский	60,6	Үзәк	96,2	Барлыгы	91,1
Барлыгы	94,7	Чыбыклы	94,6	МТС лар буенча барлыгы	92,3
Кама арты районнары:		Кузайкино	94,2	1940 нчы елның 5 нче апреленә	88,7
Черемуховский	100,0	Иске Писмән	92,6	1939 нчы елның 10 нчы апреленә	95,6
Иске Чишмә	100,0	Баулы	87,5		
Аксубай	100,0	Чишмә	83,8		
Кызыл Чапчак	100,0	Соколка	80,0		
Октябрь	100,0	Поповка	79,6		
Зирекле	100,0	Карамалы	75,5		
Биләр	100,0	Бөгелмә	70,7		
Салман	100,0	Заинский	66,7		
		Барлыгы	91,1		

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Бер пропагандист һәм аның эше турында

Кәшер авылындагы (Әлмәт районы) башлангыч партоешма янында ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр өчен түбән буын буенча түгәрәк оештырылган иде. Бу түгәрәккә барлыгы 9 кеше тартылган. Занятиеләргә йөреш уртача 50 проценттан артмый. Түгәрәккә райком пропагандисты иптәш Шамсуллин житәкчелек итә.

Хәзер бу түгәрәктә занятиеләр ВКП(б) тарихының III нче этапы буенча үткәрелә.

Түгәрәктә партия тарихын өйрәнү эше ничек куелган соң? Бу сорауга җавап итеп пропагандист иптәш Шамсуллинның бер занятиесен алып карыйк.

Соңгы вакытларда үткән занятиеләрнең берсендә, иптәш Шамсуллин занятиене башлап җибәргәндә, түгәрәк членнары алдында шушы занятиедә өйрәнеп үтелергә тиешле булган төп сорауларны куйды.

„Чит илләрнең хәрби интервенциясе башлану. Гражданнар сугышының беренче чоры" дигән беренче сорау буенча комсомолец иптәш Г. Әхмеров сүз алды. Ул сүзен бетергәннән соң анарга тыңлаучылардан берсе, Брест солыхының кайчан һәм кайсы илдә төзелүе һәм бу солыхны төзүдә Троцкийның хыянәте турында сорау бирде. Иптәш Әхмеров бу сорауларга җавап бирмәде. Аннан соң иптәш Равилов сүз алып, 2—3 сүздән генә Брест солыхы 1918 нче елда Германиядә төзелде, дип җавап бирде. Бу сорауга дөрес һәм ачык җавап бирелмәде. Пропагандист та тиешле йомгак ясамады.

— Тагын нинди сораулар бар, дигәч, түгәрәк членнарыннан берсе пропагандистның үзенә: „Россия Антанта союзыннан кайчан чыкты", „Украина радасын ничек аңларга" дигән сорауларны бирде. Пропагандист бу сорауларга: „СССР Антанта союзыннан 1918 нче елны чыкты. Украина радасы турында үзем дә ачык белмим, Белоруссия радасын гына беләм" дип кыска гына җавап бирде. Бу җаваптан түгәрәк членнары бер нәрсә дә аңламадылар һәм ул бөтенләй дөрес түгел иде.

„Германиянең сугышта җиңелүе һәм аның сәбәпләре" дигән икенче сорау буенча, комсомолец иптәш Вәлиев сүз алып сөйли башлады. Вәлиевнең һәрбер сүзеннән аның занятиегә бөтенләй хәзерләнми килүе ачык иде. Чөнки ул Германиядәге ниндидер Кызыл Армия турында сөйләде, куелган сорауга җавап бирә алмады. Пропагандист, шул ук сорау буенча Хәлимовага, аннан соң Заһировага сүз бирде, аларның сөйләүләрен сорады. Ләкин бу иптәшләр дә занятиегә хәзерләнми килгәнлектән, сөйләүдән баш тарттылар. Бу сорау буенча да, аннан соңгы сораулар буенча да сөйләүчеләр булмагач, пропагандист үзе генә сөйләде. Пропагандист иптәш Шәмсуллин үзе дә занятиегә ныклап хәзерләнеп килмәгән, шунлыктан ул бер генә сорауга да тулы җавап бирә алмады һәм түгәрәк членнарына бөтен бер нәрсә бирмәде.

Өченче Коммунистик Интернационалның төзелүе турында сүз барганда, түгәрәк членнарыннан иптәш Әмиров пропагандисттан I—II нче интернационаллар турында да кыскача гына аңлатып китүен сорады. Ләкин пропагандист моңа игътибар итмәде. Сораулар җавапсыз калдылар.

Шулай итеп, 2 сәгатьтән артык вакытка сузылган занятиедән түгәрәк членнары бер нәрсәгә дә төшенә алмыйча өйләренә таралыштылар.

Иптәш Шәмсуллин райкомның штаттагы пропагандисты. Ул үткәргән занятиеләр штаттан тыш пропагандистларга үрнәк булырга тиешләр иде. Кызганычка каршы иптәш Шәмсуллин моның киресен күрсәтә. Ул занятиеләргә хәзерлексез килә, занятиеләрдә бернинди дә күргәзмә материаллардан, альбомнардан, карталардан файдаланмый. Түгәрәк членнары алдына куелган сорауларны популярлаштереп аңлаешлы итеп куймый һәм сөйләүләрдән соң йомгак ясап бармый. Занятиеләр тын һәм күңелсез үтәләр. Шуның аркасында түгәрәк членнары арасында укуга һәм занятиегә хәзерләнеп килүгә теләк тумый.

Партиянең Әлмәт райкомы пропагандист иптәш Шәмсуллинның үз эшенә җавапсыз каравын белә торып тиешле нәтиҗә ясаганы юк.

М. Талыпов.

ПАРТИЯ ОЕШМАСЫ ЮГАРЫ УҢЫШ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ

Буденный районы „Гигант №2" колхозы янындагы башлангыч партоешмада 15 коммунист бар. Аларның күбесе турыдан-туры колхоз производствосында эшли. Партоешманың оператив житәкчелегендә колхоз язгы чәчүгә тулы хәзерлек белән каршылады.

Колхозның һәр бригадасына коммунистлар беркетелде. Алар колхозчыларга партия һәм хөкүмәт карарларын аңлаталар. Югары уңыш алу буенча тәҗрибәләрне өйрәнү өчен колхозда стахановчылар мәктәбе оештырылды. Бу мәктәпнең яхшы эшләве нәтиҗәсендә быел кышкы агрономия чаралары үткән елларга карагада күп тапкырлар уңышлы итеп үткәрелде.

Партоешма колхоз житәкчеләренең һәм бригадаларга беркетелгән коммунистларның информацияләрен системалы рәвештә тыңлый һәм аларның эшләрендәге кимчелекләрне бетерергә практик булышлык күрсәтә.

Бригадалар, звенолар һәм аерым колхозчылар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелде. Һәр бригадага агитатор беркетелде. Алар иптәш Андреевның Новосибирски өлкәсе авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә сөйләгән речен һәм башкаларны колхозчыларга җентекләп аңлаттылар.

З. Шәйхаттаров.

„Гигант №2" колхозы партоешмасының секретаре.

КОМСОМОЛ АКТИВЫНЫҢ РАЙОН СЛЕТЫ

Шушы көннәрдә Ленин районындагы комсомол-физкультура активының слеты булды һәм анда 200 кеше катнашты.

„Кышкы сезонда физкультура эшләренең йомгаклары һәм алда торган бурычлар турында" ВЛКСМ райкомының хәрби-физкультура бүлеге мөдире иптәш Ганцаревич доклад ясады.

Докладчы кышкы сезонда аерым спорт җәмгыятьләренең эшләре күренерлек яхшыруы турында сөйләде. Чаңгыда йөрү буенча норма тапшыруга „Советлар канаты" җәмгыяте 120 кеше, „Строитель" 112, Монолит 80 кеше хәзерләгән һәм башкалар. Байтак кына секцияләр төзелгән һәм алар ГТО га нормалар тапшыруга хәзерлек алып баралар.

Шуның белән бергә, докладчы комсомол оешмаларының бу мәсьәлә белән җитәрлек шөгыльләнмәүләрен һәм спорт җәмгыятьләренә тиешенчә булышмауларын күрсәтеп үтте.

Актив җыелышы Баку физкультурникларының чакыруларын кабул итте һәм Ленин районы комсомолецларын җәйге спорт сезонын оешкан рәвештә үткәрүгә чакырды.

В. Прокофьев.

Иләеш районы, „Свободный труд" колхозы членнары Коминтерн исемендәге радиостанциядән соңгы хәбәрләр тыңлыйлар. С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Партиянең район конференциясеннән соң

(ВКП(б) ның Сталин райкомы секретаре иптәш Тышкевич белән сөйләшү)

ВКП(б) нын Сталин район конференциясендә райкомның һәм шулай ук башлангыч партия оешмаларының эшендә зур гына җитешсезлекләр яшәп килүе күрсәтелгән иде. Районның эре предприятиеләрендә („Красный путь", Вахитов исемендәге жиркомбинат, Энергокомбинат һ. б.) 1939 нчы елны промфинплан үтәлмәде. Шулай ук 1940 нчы елның беренче кварталында да бу заводлар начар эшләделәр. Мәсәлән, „Красный путь" заводы беренче кварталда промфинпланны 90 процентка, жиркомбинат 72 процентка, ясалма каучук заводы бары тик 47 процентка гына үтәделәр.

Районда политик-масса эшләре тиешле югарылыкта түгел иде. Күп кенә предприятиеләрдә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнү эше йомшак куелган иде.

Партиянең район конференциясе, җәмагат оешмаларында эшләрнең һич тә канәгатьләнерлек булмавын күрсәтте. Мәсәлән, Сугышчан Алласызлар Союзының күп кенә ячейкалары хәтта аның район советы да оештыру ягыннан рәсмиләштерелмәгәннәр иде.

Район партия конференциясеннән соң райкомның яңа составы югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү өчен байтак эшләр башкарды. Пленум членнары артта калучы предприятиеләргә беркетелделәр. Махсус бригада Казан тимер юлы станциясендә эшләрнең торышын тикшерә һәм аның нәтиҗәсе райкомның бюро утырышында каралачак.

Предприятиеләрнең беренче кварталда ничек эшләүләре, партиянең Бөтенсоюз конференциясен һәм Татарстанның XX еллыгын лаеклы каршылау өчен хәзерлек эшләрен җәеп җибәрү турында завод-фабрика директорларының киңәшмәләре үткәрелде.

Районда политик-масса эшләрен яхшырту мәсьәләсендә дә байтак кына практик чаралар үткәрелде. Мәсәлән, агитколлектив җитәкчеләренең киңәшмәсе үткәрелде. Анда, СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясе материалларын өйрәнүне һәм Беренче Майга хәзерлек эшләрен оештыру мәсьәләләре тикшерелде.

Оештыру мәсьәләләре буенча райком системалы рәвештә башлангыч партоешма секретарьларының семинарларын үткәрде. Ул семинарларда секретарьлар партия сафларына кабул итү, партия документларын рәсмиләштерү, коммунистларны учетка алу, комсомолга җитәкчелек һәм башка мәсьәләләр турында инструктаж алдылар.

Райком бригадасы тарафыннан 4 нче ясалма каучук заводы янындагы партоешмада „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнүнең торышын тикшерү тәгәлләнде. Бу мәсьәлә 16 нчы апрельдә бюро утырышында каралачак.

Районда дингә каршы пропаганда эшләрен көчәйтү йөзеннән райком Сугышчан Аллаcызлар Союзы ячейкаларының отчет-сайлау җыелышларын үткәрү һәм район конференциясен чакыру турында карар кабул итте.

Партиянең район конференциясеннән соң райком тарафыннан үткәрелгән практик чараларның кайберләре әнә шулар.

Шушы чаралар нәтиҗәсендә хәзерге вакытта кайбер промышленность предприятиеләренең эшендә нык кына борылыш сизелә башлады. Мәсәлән, мехкомбинат беренче квартал планын 100 процент, Казан фетр фабрикасы 107 процент, „Красный восток" заводы 113,7 процент, икмәк заводы 115,7 процент һәм Пламя заводы 166 процент итеп үтәде.

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

ЧИСТАЙ, 11 апрель. (Телефон буенча). Чистай шәһәрендәге суднолар ремонтлау заводының токарьный цех эшчеләре Беренче Май бәйрәмен производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен көрәшәләр, социалистик ярыш договорларын яңартып төзиләр.

Йөкләмәләр практик эш белән ныгытыла. Мәсәлән, берьюлы 4—5 станокта эшләүче атаклы стахановчы, район советы депутаты иптәш Гибалин айлык планны әледән-әле 700—800 процент итеп үти һәм айлык хезмәт хакы 1.800—2.000 сумнан кимеми.

Стахановчы иптәш Боварницин февраль ае нормасын 500 процентка үтәде һәм 975 сум хезмәт хакы алды. Цехның стахановчыларыннан Смирнов һәм Носков иптәшләр дә производство планын 250—300 процент итеп үтиләр. Беренче Май алды ярышын киң җәелдерү нәтиҗәсендә токарьный цех февраль ае планын 159 процент, март ае планын 110 процент итеп үтәде.

К. Исламов.

Тагын да яхшырак эшләү өчен

Татпромсовет системасындагы артель коллективлары 1 нче Май бәйрәменә һәм республикабызның XX еллыгына эшлекле рәвештә хәзерләнәләр. Производство планын вактыннан элек арттырып үтәү, массовый тәрбия эшләрен тамрыннан яхшырту— ярышта алган төп йөкләмәләрнең берсе.

Артель белән артель, бригада белән бригада ярышы һәм шулай ук индивидуаль ярыш көннән-көн киң колач ала һәм бу ярыш үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә. Мәсәлән, „Швейник", „Кызыл Йолдыз", „Кызыл Масра", „Заря", „Ил", „Ударник" һәм башка шундый дистәләрчә артельләр 1940 нчы елның беренче квартал планын арттырып үтәделәр. Алар хәзер апрель ае планын 20 нче числога үтәү өчен большевикларча көрәшәләр.

Татшвеймехпромсоюз, Пищпромсоюз һәм Текстильтрикотажпромсоюз артельләре дә алдынгылардан калышмыйлар. Алар үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә, әледән-әле яңа казанышлар яулап алалар. Татпромсовет правлениесе ярышта җиңеп чыккан алдынгы артельләрне бүләкләү өчен 10 мең сум акча билгеләде.

Артельләрдә культура-тәрбия эшләре яхшырганнан-яхшыра бара. Татпромсовет правлениесенең культура бүлеге янында татар-башкырт хатын-кызлары хоры, татар биюе, рус халык җырлары, хоры оештырылды. Беренче май тантанасында алар үзләренең беренче концертларын бирәчәкләр.

Артельләрдә эшләүче комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр һәр эш тармагында алдынгылык күрсәтәләр. Мәсәлән, Трикотаж артелендә Фәтхурахметова, Низаметтинова, Черемискина, Пименова, Мортазина, Гафиятуллина һ. б. иптәшләр үзара социалистик ярышка чыгып, Беренче Май бәйрәмен стахановча эшләү һәм оборона значокларына нормалар тапшыру белән каршылау өчен көрәшәләр.

И. Кәрим.

Ярыш нәтиҗәсе

Икенче тегү фабрикасы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары орденлы Татарстан республикасының XX еллыгын яңа уңышлар белән каршылау өчен үз өсләренә йөкләмәләр алганнар иде. Алар бу йөкләмәне үтәү өчен көрәштә зур гына уңышларга ирештеләр.

4 нче цех стахановчылары хезмәт җитештерүчәнлегенең яңадан-яңа күтәрелешен тудыралар. Иптәш Гаврилова агрегатында эшләүчеләрдән иптәш Болошева айлык планны 135 процент, иптәш Гаврилова 125 процент, иптәш Заһриева 180 процент итеп үтиләр. Планны арттырып үтәү белән бергә, алар яхшы сыйфатлы продукция эшләп чыгаралар.

Бу цехтагы эшчеләр үзара ярышып эшлиләр. Алдынгы стахановчы иптәш Коржиманова иптәш Харитонова белән ярыша. Иптәш Коржиманова айлык планны 187 процент итеп үти. Иптәш Харитонованың да күрсәткечләре аннан ким түгел.

Г.

ПАРТИЯ ПОРУЧЕНИЕЛӘРЕ

Тархан районы, „Марс" колхозы янындагы башлангыч партоешмадагы (секретаре иптәш Мисбахов) барлык коммунистларга да партия поручениеләре бирелгән. Мәсәлән, иптәш Әхүдиев стена газетасы редакторы, иптәш Вәлиев исә Осоавиахим оешмасында эшли. Алар үзләренә тапшырылган эшләрне яхшы итеп башкаралар. Поручениеләрнең үтәлеше системалы рәвештә тикшерелә.

Аерым коммунистларның поручениеләрне ничек үтәүләре турында партия җыелышларында информацияләр тыңлана.

Партия оешмасы колхоз производствосына ныклы җитәкчелек итә. Язгы чәчүне уңышлы үтәү өчен барлык коммунистларга да звеноларда, бригадаларда масса-политик эш алып бару йөкләнелде.

Зәкия Бикбаева.

ТАТАР МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ

Хөкүмәтебезнең һәм партиябезнең 1938 нче ел 13 нче март карарының әһәмиятен тирәнтен аңлап һәм дәрес бирү эшен шушы карар нигезендә үзгәртеп кора алган мәктәпләр рус телен укыту буенча өлгерештә гүзәл күрсәткечләр бирәләр. 1939—40 нчы уку елының беренче яртысы азагында үткәрелгән контроль диктантлар моны ачык күрсәттеләр. Мәсәлән, Казанның 13 нче номерлы урта мәктәбендә, Мамадышның 2 нче номерлы урта мәктәбендә һәм башкаларда укучылар диктантларны яхшы һәм дөрес язганнар.

Ләкин Татарстанның кайбер татар мәктәпләрендә укучыларның рус теле буенча белем дәрәҗәләре канәгатьләнерлек дип әйтеп булмый әле.

Уку елының беренче яртысы азагында үткәрелгән контроль диктантларда күп кенә укучыларның рус теле буенча ялгышлары түбәндәгеләргә кайтып кала:

Укучылар рус алфавитын тиешенчә белмиләр һәм рус хәрефләрен латин алфавиты хәрефләре белән бутыйлар. Бу исә X нчы класслардагы кайбер укучылар өчен дә гадәт булып киткән, **б** һәм **в** хәрефләрен генә түгел, башка хәрефләрне дә бутыйлар: **м** урнына **т**, **п** урнына **р**, **р** урнына **ч** язалар һ. б. Бу бутау сүзләрнең бозылуына китерә.

Е һәм **и** хәрефләрен дөрес куллана белмиләр, еш кына **е** урнына **и** һәм, киресенчә, **и** урнына **е** язалар (**земовка, уведили, жезнь** һ. б.). **О** һәм **у** хәрефләрен дөрес куллана белмичә, еш кына аларны бутыйлар (погода урнына **погуда**, родную Москву урнына **родною Москво** дип язалар). **Е** һәм **ю** хәрефләре арасындагы аерманы шулай ук сизмиләр һәм аларны дөрес куллана белмиләр (**юг урнына ег, еж** урнына **юж**, самолет урнына **самолот, самолют** дип язалар һ. б.). Сүз азагындагы **ый** һәм **ий** бетемнәрен дөрес үзләштермәү нәтиҗәсендә ялгыштырып, „Зеленый Московский аэродром" урнына, „**Зелони Московски аэродром**", „это тебе обязаны мы нашей победой" урнына „**это теве обязаний мы нашы победое**" дип язалар.

Укучыларның бик күбесе диярлек сүзнең уртасында һәм азагында килә торган **л** хәрефеннән соң нечкәлек билгесе куеп, „**в тольпе**", „**выпольнили**" һ. б. дип язалар. Тартык аваз бирә торган **д** һәм **т** хәрефләрен бутап, „уютная" урнына „**уюдная**", „летной погоды" урнына „**ледной поготы**" һ. б. дип язалар. **Ж, ш, щ, ч** хәрефләрен бутап „**освешчение**", „**обшей комнаты**", „**зимовшики**" һ. б. дип язалар.

Башлангыч мәктәптә үк ничек язылуы билгеле булырга тиешле сүзләрдә дә басымсыз сузык авазларда күп ялгышлар җибәрелә. Мәсәлән, „несколько", „**сбаводное**"(свободное) „время" „**радной**", „**сталится**" (столица) һ. б. дип язалар.

Һәр кешегә билгеле булган һәм күп кулланыла торган сүзләрне, мәсәлән, „сахар" сүзен „**сахер**", „**сахор**", „**сахарь**" дип, „библиотека", сүзен „беблетека" „библитека" дип; „курс" сүзен „**курц**", „**курст**", „**кортц**" дип язалар.

Бу ялгышлар күп кенә укучыларның гади җөмлә төзелешенең төп законнарын аңлап җиткермәүләрен күрсәтәләр.

Укучыларның язу эшләренә, бигрәк тә уку елының беренче яртысы азагында үткәрелгән контроль диктантларына ясалган анализ күп кенә татар мәктәпләрендә рус теле укытуның куелышы әле һаман да канәгатьләнерлек түгел дигән нәтиҗәне ясарга нигез бирә. Димәк, „Милли республикалардагы һәм өлкәләрдәге мәктәпләрдә мәҗбүри рәвештә рус теле укыту турында" СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел 13 нче март карарын тормышка ашыру өчен җитәрлек көрәш алып барылмый әле.

Кайбер татар мәктәпләрендә рус теле укытуның канәгатьләнерлек куелмавының сәбәпләрен, барыннан да элек, укытучының эшеннән эзләргә кирәк. Рус теле укытучыларының күбесе дәрес бирү эшен РСФСР Наркомпросы программасын формаль үтәүгә кайтарып калдыралар—мондый укытучылар балаларга рус телен түгел, бәлки стабиль дәреслекләр буенча рус теле грамматикасын өйрәтәләр.

Һәрбер телне һәм, билгеле, рус телен дә өйрәткәндә укытучыларның кайберләре хәл иткеч төп эш төрләрен аңламыйлар. Укучыларда рус теле запасын туплау (сүзлек өстендә эшләү), гади һәм кушма җөмләләр төзүнең законнарын теоретик һәм практик өйрәтү, җанлы сөйләү теле, аның мәгънә ягы, синтаксис һәм стиль ягыннан төзелеше өстендә ныклы эш алып бармыйлар. Бу эшләр исә башлангыч мәктәпнең III нче классларыннан алып, урта мәктәпнең X нчы класслары тәмам булганга кадәр үткәрелергә тиешле.

Сүзләр өстендә эшләүне дөрес куюга зур игътибар бирелергә тиеш. Рус теле, әдәбияты һәм әдәби уку буенча һәрбер дәрес укучыларны яңа сүзләргә баетырга тиеш. Укучы һәрбер яңа сүзне тәмам үзләштерергә, ул сүз аның лексиконына керергә тиеш. Ә моның өчен ул аның мәгънәсен тәмам дөрес аңлау, дөрес әйтү һәм язу белән генә калмаска, бәлки аның төзелешен, морфологик составын да аңларга, шулай ук бу сүзне җөмләдә күрергә, синтаксис ягыннан аның ролен аңларга, башка сүзләр унае белән бу сүз очравы мөмкин булган үзгәрешләрне дә аңларга тиеш.

Грамматик өйрәнүнең бөтен төрләре белән бергә алып барыла торган язу эше (иҗади күчереп язу, диктантның төрле төрләре, үзенчәләтеп язу һәм башкалар)—тел буенча практик занятиеләрнең иң яхшы төре. Контроль эшләр укытучы төзәткәннән соң орфография ягыннан җентекләп өйрәнелергә тиешләр.

Ләкин бу әле без грамматиканы өйрәнүнең әһәмиятенә игътибар бирмибез дигән сүз түгел. Фонетика, морфология һәм синтаксис нигезләрен белми торып, грамматик өйрәнү дә мөмкин булмас иде. Ә грамматик өйрәнү укучыларның грамматика өлкәсендәге белемнәрен тирәнәйтә һәм киңәйтә, җанлы телнең иң яхшы үрнәкләренә анализ ясау белән аларга грамматиканы аңлы рәвештә үзләштерергә ярдәм итә. Системалы язу күнегүләре, сүзләр өстендә эшләүнең дөрес куелуы һәм грамматик тикшерү булмаганда грамматиканы өйрәнүнең рус телен үзләштерү өчен файдасы аз. Ә укучыларның язу эшләрендәге ялгышларның характеры грамматик өйрәнүнең бөтен төрләре белән бәйләнгән сүзләр өстендә эшләүгә һәм язу күнегүләренә кайбер мәктәпләрдә житәрлек әһәмият бирелмәүне күрсәтә.

Бер мисаль китерик:

VII нче класс укучыларыннан берсе диктанттагы „какой теплотой светились его глаза, когда он обнимал нас по очереди" дигән җөмләне „**какое те платой свителис** его глаза..." дип, ә икенчесе „**какое тивльетое цвителис** его глаза..." дип язган.

„Теплотой" дигән сүзне ни өчен берсе „те платой", икенчесе „тивльетое" дип язган? Чөнки бу гади сүз аларга таныш булмаган, алар аны аңламаганнар. Беренче укучы „плата" дигән сүзне белгән һәм язган вакытта сүз „плата" турында бара дип уйлаган булса кирәк. Икенчесе гомумән бу сүзне аңламаган һәм ничек ишетсә шулай язган.

Укытучы бу сүзләрнең составын укучыларга күрсәтмәгән, аларның нинди тамырдан төзелгәнлекләрен аңлатмаган, укучыларда бу сүзләрнең нык лы график образын калдырмаган, җанлы телдә аның үзгәрешләрен күрсәтмәгән.

Укучыларның язу эшләре аларның тыныш билгеләрен дөрес куя белмәүләре белән дә характерлана. Бу да гади һәм кушма җөмләләрне өйрәнүгә һәм җөмләнең синтаксис ягыннан төзелүен тикшерүгә укытучының тиешле игътибар бирмәвенең нәтиҗәсе.

Димәк, республиканың күп кенә татар мәктәпләрендә рус телен укыту эше канәгатьләнерлек куелмаган дигән сүз. Бу исә бездән СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитете карарын үтәү буенча тагын да җиддиерәк эш таләп итә.

ГР. КАМИНСКИЙ.
Укытучыларның белемнәрен күтәрү институтының фәнни сотрудникгы.

Агрономия киңәшләре

ДОЛГУНЕЦ ҖИТЕН ЧӘЧҮНЕ ЮГАРЫ СЫЙФАТЛЫ ИТЕП ҮТКӘРЕРГӘ

Өченче бишьеллык ахрына СССР да җитенннең һәр гектарыннан кимендә 4,6 центнер сүс уңышы алынырга һәм шул ук вакытта сүснең сыйфаты күтәрелергә тиеш. Партиянең XVIII нче съездының күрсәтмәсе әнә шундый.

Татарстан АССР колхозларында бу күрсәтмәне уңышлы итеп үтәргә бөтен мөмкинлекләр бар. Алдынгы колхозларның һәм җитен осталарының тәҗрибәләре моны ачык күрсәтә. Үткән елны Чепья районының „Красный Яр" колхозы долгунец җитененнән һәр гектарыннан уртача 4,2 центнер сүс һәм 4 центнер орлык уңышы алды. Кукмара районы, Сталин исемендәге колхозның звеновоы иптәш Ишмөхәмметов җитененнән һәр гектарыннан бернечә елдан бирле инде уртача 4—5 центнер сүс уңышы алып килә.

Ләкин, гомумән алганда, ТАССР күләмендә долгунец җитен уңышы һаман да түбән, гектарыннан уртача бары 1,5—2,0 центнер тула алына. Үткән елны республикабызда җитен сүсе уңышы бары 0,7 центнер булды.

Җитен уңышының шулай түбән булуының төп сәбәбе, барыннан да элек, долгунец җитенгә карата билгеләнгән агрономия чараларын тулы итеп һәм дөрес үткәрмәүдә.

Долгунец җитененнән югары уңыш алу өчен нәрсә эшләргә кирәк соң?

Җитен чәчү өчен чүпсез, уйсу җирләрдәге иң яхшы участкыларны билгеләргә кирәк.

Фәнни учреждениеләренең материаллары һәм җитенчелек стахановчыларының тәҗрибәләре җитен өчен тимофеевка катнаш клевер (ике ел чабып алынганнан соң) иң яхшы элгәр булып исәпләнгәнен күрсәтәләр. Тирес белән ашланган чиста парлар да шулай ук җитен өчен начар элгәр түгел. Бөртекле сабан культуралары җитен өчен яхшы элгәр була алмыйлар. Чөнки ул культуралардан соң туфрак һәр вакытта да дип әйтерлек чүпләнеп кала һәм туфракның структурасы бозылган була. Җитенне ике ел рәттән бер ук урынга чәчәргә һич тә ярамый.

Чәчүлек җитен орлыгы бигрәк тә яхшы сыйфатлы булырга тиеш. Моның өчен җитен орлыгын элек „Триумф" сортировкасы белән, аннан соң трешетка, триер һәм вини сортировкалары белән таратырга кирәк. Чәчүгә ике-өч көн калгач җитен орлыгы Давыдов препараты белән агуланырга тиеш.

Дым туплау һәм тупланган дымны саклап калу өчен, җитен участкыларында туңга сөрелгән җирне яз көне ике эздән иртә тырмалау үткәрергә кирәк.

Клевердан бушаган җирләргә һәм азот белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителгән туфракларда җитен астына фосфорлы һәм калилы ашлама кертергә киңәш бирелә. Стахановчылар минераль ашламаларга өстәмә итеп җирле ашламаларны (көлне һәм кош тизәген) җитен астына кертү белән бик зур уңышлар ирешәләр. Мәсәлән, Житомир өлкәсе, Сталин исемендәге колхозның җитенчесе иптәш Ждановская үткән елны җитененнең һәр гектарыннан уртача 27 центнер сүс һәм 17,6 центнер орлык уңышы алды. Иптәш Ждановская һәр гектарга 10 центнер көл, 10 центнер кош тизәге, 10 центнер суперфосфат, 3 центнер кали тозы һәм 2 центнер селитра керткән.

Җитен чәчү өчен яз көне туфрак хәзерләгәндә һәрбер участокка карата аерым рәвештә ни итәргә кирәк. Участокның туфрагының үзенчәлеген, туңга сөрүнең сыйфатын һәм башка якларны исәпкә алырга кирәк. Җитен чәчү өчен яз көне туфрак хәзерләү туңга сөрелгән җирне 10—12 сантиметр тирәнлектә культивацияләүдән, шуның артыннан ук ике эздән тырмалаудан гыйбарәт. Туңга сөрелгән җирне яз көне яңадан сөрү туфрактагы дымны югалтуга сәбәп була. Шуңа күрә бу эштән сакланырга, туңга сөрелгән җирне яз көне яңадан сөрүне аерым хәлләрдә генә, туфрак бик тыгызланган чакта гына, үткәрергә мөмкин. Җитенгә кадәр күп еллык үлән (тимофеевка катнаш клевер) чәчелгән, печәне чабылып алынган җирләрне яз көне буразналарга аркылыга һәм буйга дисклы культиваторлар белән эшкәртергә кирәк. Шуннан соң бу җирләрне тырмаларга кирәк.

Астагы катлаудан дым өскә катлауга яхшырак күтәрелсен өчен һәм җир өсте тигезләнсен өчен җитен чәчелгән җирне катокларга кирәк. Яңа үзләштерелә торган җирләрдә кольчатый катоклар, ә электән сөрелеп килгән җирләрдә гади катоклар кулланырга кирәк.

Җитенне бөртекле культуралар белән бер вакытта чәчәргә кирәк. Орлык 1,5—2,0 сантиметр тирәнлеккә кадәр күмделергә тиеш. Моның өчен рәт аралары тарайтып эшләнгән 17 рәтле махсус җитен машиналарыннан файдаланырга кирәк. Мондый машиналар булмаган колхозларда җитенне кул белән (орлыкның 50 процентын буразнага аркылы, ә 50 процентын буйга) чәчәргә кирәк. Чөнки бөртекле культура чәчү машиналары белән җитен орлыгын 1,5—2,0 сантиметр тирәнлеккә күмдерү бик кыен. Ләкин җитен кулдан чәчелә торган участкылар бик яхшылап эшләнгән булырга тиеш. Кулдан чәчелгән орлыкны күмдерү өчен гадәттә җиңел тырмалардан файдаланыла.

Р. Абдразәков.

Татнаркомзем агрономы.

Юл төзелеше алдынгылары.

Арча районы, Корайван авылы, „Кызыл тау" колхозы членнары юл төзү материалларын хәзерләү һәм аларны төзелеш объектларына ташу эшен срогыннан элек, 152 процент итеп үтәделәр. Колхозда даими юл төзүчеләр бригадасы төзелде. Бу бригада „Бакча Сарай" колхозындагы юл төзүчеләр бригадасы белән ярышта җиңеп чыкты.

Бригада җитәкчесе иптәш Саляховның хезмәтне яхшы оештыруы нәтиҗәсендә, бригада членнары Хәбибуллин, Тимербаев, Гатауллин, Хуҗина һәм Әхмәдуллин иптәшләр таш чыгару һәм ташу эшендә көнлек планны һәр вакыт 150—160 процент итеп үтиләр. Район юл бүлеге юл төзү материалларын ташуны районда беренче булып тәмамлавы өчен „Кызыл тау" колхозы председателе Шәпиев, бригадир Салахов, бригада членнары Әхмәдиев, Гатауллин һәм Хуҗина иптәшләрне 100 әр сум акча белән бүләкләде.

А. Маннанов.

* *

Фергана каналы төзелеше тәҗрибәсен юллар төзелешенә күчерү турында Столбище районының „13 лет Октября" колхозчылары чакырышы белән Саба районы колхозларында зур күтәренкелек белән каршыланды. „Сулә", „Кызыл партизан", „Радио" һәм башка колхозлар юл төзелеше буенча үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә, 1940 нчы ел төзелеш сезонына тулы хәзерлекне тәэмин иттеләр. Алар төзү материалларын эш объектларына ташу планын арттырып үтәделәр.

Юл төзү эшендә эшләүче бригадирлардан Вәлиев, Закиров, Гыйлметтинов, колхозчылардан Вәлиев Гариф, Мифтахов, Зиннуров, Хажиева, Сибгатуллин, Фәхриев, Гыйлаҗов, Төхфәтев иптәшләр аеруча яхшы эшләп, үзләрен стахановчы итеп таныттылар.

Бу алдынгы колхозлар төзелеш сезонына хәзерлек чорында ирешелгән уңышларны ныгыту өчен, юл төзелеше планын республикабызның XX еллык бәйрәменә үтәүне тәэмин итү өчен хәзердән үк практик чаралар күрәләр.

Г. Нәгыймов.

Түтәл бакчамнан югары уңыш алырмын

Ленин исемендәге күн заводында байтак эшчеләр һәм хезмәткәрләр берничә еллардан бирле түтәл бакчачылыгы белән шөгыйльләнеп киләләр. Алар бу эшнең файдалы булуын үз тәҗрибәләрендә күрделәр. Көлләү цехы эшчесе иптәш Сергин үз участкысын башкаларга үрнәк булырлык итеп эшли. Үткән елны ул 30 капчык бәрәңге һәм төрле яшелчә җыеп алды. Комлев, Смирнов һәм башка иптәшләр дә шул ук күләмдә яшелчә җыеп алдылар. Алар үзләре үстергән яшелчәдән кыш буе файдаландылар. Аларның яшелчәләре бөтен ел буена җитәрлек.

Заводта индивидуаль түтәл бакчасы белән кызыксынучылар күп. Партия һәм профсоюз оешмалары бу әһәмиятле эшкә зур игътибар бирәләр. Цехларда консультацияләр, аңлату эшләре үткәрелә. Түтәл бакчасы үстерергә теләүчеләргә участкылар беркетелә.

Үткән елны миңа индивидуаль торак йорты салу өчен дәүләт тарафыннан 1.100 сум ссуда бирелде. Мин яңа йорт салдым. Шул ук вакытта миңа җир участкысы да бирелде. Бу участкыдан быел мин семьяма ел буена җитәрлек яшелчә җыеп алырга телим. Хәзер бакчаны койма белән әйләндереп алам. Җир бик яхшы.

Миннән башка тагын 13 кеше дәүләт тарафыннан ссуда алып, үзләренә торак йортлары салдылар. Аларның да җир участкылары бар. Алар быел түтәл бакчачылыгы белән шөгыйльләнергә булдылар.

Участкылар алу гына җитми. Яшелчәдән югары уңыш алу өчен без башкаларның тәҗрибәләреннән файдаланырга, җирне ашларга, аны тәрбияләргә тиешбез. Һәрбер эшче, хезмәткәр партия һәм Совет хөкүмәтенең кайгыртучанлыгына эш белән җавап бирергә, югары уңыш җыйнап алырга тиеш.

З. Мортазин.

ФАНЕРА ЗАВОДЫ НИ ӨЧЕН НАЧАР ЭШЛИ?

Промышленностьның башка предприятиеләре шикелле үк, Зеленодольский шәһәрендәге 3 нче номерлы фанера заводы коллективы да Москва инструментальщиклары һәм Казан мехчылары чакыруына бердәм рәвештә кушылды. Ярты еллык планны вактыннан элек, республикабызның XX еллыгына тулы үтәү йөкләмәсен алды.

Завод җитәкчеләре массаның бу активлыгына оператив җитәкчелек итәргә, алган йөкләмәләрне практик эш белән ныгыту өчен барлык чараларны күрергә, кирәкле шартлар тудырырга тиешләр иде. Кызганычка каршы, заводта мондый эш күренми әле. Беренче кварталда план үтәлеше сан һәм сыйфат ягыннан да өзелде.

Бу артта калуның төп сәбәбен, барыннан да элек, завод һәм цех җитәкчеләренең борыла алмаучанлыклары һәм эшкә тоткарлык ясаучы күренешләргә каршы көрәшмәүләре белән аңлатырга мөмкин. Эшчеләрнең һәм машиналарның эшсез торулары массовый төс алган. Мәсәлән, 1 нче кварталда ябыштыру цехы буенча гына да 4.435 сәгать эшсез торылган. Гомумән завод буенча эшсез торуларның күләме 14,1 процентка җитә. Производство расходлары 61 мең сумга артык тотылган. Шулай да, бу аяныч факт завод җитәкчеләрен һич борчымый, эшсез торуларны бетерү өчен җидди чаралар күрелми. Ябыштыру цехындагы вагонеткаларның шарикоподшипниклары булмау аркасында, аларның яртылаш кына файдаланылулары, цехларны чимал белән тәэмин итү эшенең чиктән тыш начар оештырылуы әнә шул турыда сөйли.

Завод цехларын чимал белән үз вактында һәм өзлексез рәвештә тәэмин итү, аңардан рациональ файдалану—план үтәлешен тәэмин итүдә төп шартларның берсе булып тора. Ләкин чимал бирҗасы начальнигы иптәш Чаплыгин моны аңлап җиткермәгән әле. 1940 нчы елның 1 нче кварталында завод чимал белән бары 50 процентка гына тәэмин ителгән. Ул гына да түгел, булган материалларны саклау эше җинаятьле рәвештә начар оештырылган. Бу өлкәдә узган елгы ялгышлар быел да кабатлана. Чималны саклау өчен махсус урын хәзерләнмәгән. Алар ачык һавада ятып бозылалар. Соңгы вакытларда чимал китерү эше тизләтелде, һәр көн саен диярлек 15—16 вагон чимал китерелеп тора. Ә менә аны тизлек белән кабул итү, вагоннардан бушату эше белән һич кем кызыксынмый. Вагоннарның үз вактында бушатылмаулары өчен завод быел Казан тимер юлына 4 мең сум штраф түләгән. Чималны бушату эшен механикалаштыру һәм тизләтү турында эшчеләр тарафыннан бирелгән тәкъдимнәр әле дә булса тормышка ашырылмаган. Хәзерге көндә 1 мең кубометрдан артык чималның су астында калу, сафтан чыгу куркынычы бар.

Киң куллану товарлары эшләп чыгаручы утиль цехының бик начар эшләвен аеруча әйтергә кирәк. Завод директоры иптәш Зарифуллин бу цехка ятим бала итеп карый. Цехның нормаль эшләве өчен кирәк булган элементарь шартларны да тудырмый. Мәсәлән, церкуль станогының кайбер частьләре алмаштыруны сорыйлар. Строгаль һәм токарь станокларына да шулай ук ремонт таләп итәләр. Кадак һәм спирт лагы өзеклек белән бирелә. Менә шундый сәбәпләр аркасында, бу цех беренче квартал планын 73 процентка гына үтәде, 171 мең сумлык продукция биреп җиткермәде.

Социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итү, хезмәт дисциплинасын ныгыту заводта онтылган тармакларның берсе. Заводта стахановчыларның бай тәҗрибәләрен уртаклашу эше оештырылмаган. Сибгатуллин һәм Захаров шикелле үз нормаларын әледән-әле 150—160 процентка җиткереп үтәүче алдынгы бригадирларның тәҗрибәләре артта калучыларга күчерелми. Ярыш договорларының үтәлеше бер кем тарафыннан да тикшерелми. Завком председателе иптәш Кулеевич бу турыда сайлаучыларның наказларын үтәми. Әллә нигә бер, хәзерлексез үткәрелә торган производство киңәшмәләренең бик урынлы тәкъдимнәре дә нәтиҗәсез калдырылалар.

План үтәлмәүнең сәбәбен кайбер цех җитәкчеләре эш көчләре җитешмәүгә кайтарып калдырырга маташалар. Ләкин алар булган эш көчләреннән файдалану эшенең чиктән тыш начар оештырылуын күрмиләр. Тиешле эш һәм тормыш шартларының тудырылмавы аркасында эш көчләренең агылышы монда коточкыч зур күләм алган. Мәсәлән, узган елны заводка 1.500 кеше алынган булса, 1.600 кеше эштән киткән. Бу елның беренче кварталында 300 кеше эшкә алынган, 333 кеше эштән киткән. Бу факт үзе генә дә тәрбия эшләренең никадәр начар оештырылуын ачык күрсәтә.

Югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләр заводның партия оешмасы һәм ВКП(б) Шәһәр Комитеты күз алдында кабатланалар. Шуңа карамастан, тиешле нәтиҗә ясалмый, булган җитешсезлекләрне бетерү чаралары күрелми.

3 нче фанера заводының бу кадәр начар эшләве һич чыдарлык хәл түгел. Йөзләрчә стахановчыларның һәм уннарча бригадаларның үз планнарын арттырып үтәүләре заводта дәүләт планын тулы үтәү өчен бөтен мөмкинлекләр барлыкны күрсәтәләр. Тик бу мөмкинлекләрдән файдалана белергә, эшкә җитәкчелек стилен яхшыртырга гына кирәк.

К. Халиков, И. Фәйзуллин.

ЛОМОНОСОВ

(Үлүенә 175 ел тулу уңае белән)

Михайло Васильевич Ломоносов 1711 нче елны туган. Бу вакытта Петр 1 нче шведларга каршы җиңүле сугыш алып бара иде, ул Балтыка ярлары өчен булган мәңгелеккә килгән бәхәсне хәл итә иде.

Петрның энергиясе һәм омтылышы, аның армияне көчәйтү турында, фабрикалар, заводлар һәм верфьләр төзү турында кайгыртуы—болар бөтенесе дә Россияне Европадагы дәүләтләрнең нинди белән генә булса да бер дәрәҗәгә куюга юнәлдерелгән иде.

Ил белгечләргә гаять дәрәҗәдә мохтаҗ иде, халык практик белемнәргә сусаган иде. Россиянең төньягында белемгә омтылыш аеруча көчле иде, монда диңгез буенда яшәүчеләр борынгы заманнардан ук Архангельск аркылы Көнбатыш белән сәүдә итеп киләләр иде. Яшь Ломоносовта бу белемгә мохтаҗлык тыела алмаслык сусауга әйләнде һәм ул аны туган җирен ташлап китәргә мәҗбүр итте.

„Рус фәненең атасы" булачак кеше толып, колаклы бүрек һәм киез-итек киеп, 19 яшьлек егет чагында җәяүләп Москвага укырга килә.

Аның Москвада, славян—грек—латин академиясендә үткәргән еллары аның өчен авыр мохтаҗлыклар чоры булды. Соңыннан ул үзе турында: „Шулай итеп мин 5 ел яшәдем һәм фәнне ташламадым" дип язды.

Фәннәр Академиясе аны тау эшен өйрәнү өчен чит илгә җибәрә. Ломоносов 5 ел чамасы Германиядә тора. Россиядән үзенә тиешле акчаларны ала алмаганлыктан ул бурычка керергә һәм мохтаҗлыкта яшәргә мәҗбүр була.

Ләкин кыенлыклар аны какшатмыйлар. Ул көч җинап һәм фәндә яңа сүз әйтә алачагына ышанып Петербургка кайта.

Ләкин барсы да чит ил кешеләреннән торган академиклар рус галимнәренең—Академиянең яшь фәнни работникларының күтәрелүенә төрлечә тоткарлык ясыйлар. Аларны канцелярия чиновникларына әйләндерәләр.

Ломоносов ризасызлык күрсәтүчеләргә җитәкчелек итә башлый һәм чит ил кешеләренең башбаштаклыгына каршы кискен көрәш алып бара. Академия җыелышын хурлаган өчен ул төрмәгә ябыла һәм анда 7 айдан артык утырып чыга.

Ломоносовның бөтен тормышы Академиядәге искелеккә каршы, алдынгы фән идеяләре өчен батырларча көрәш белән үтте.

Ломоносов Россиядә материалистик философиянең иң күренекле вәкилләреннән берсе булды, ул фәндә һәм философиядә схоластикага каршы кискенлек белән чыкты. Ул безнең илебездә табигый-фәнни материализмга нигез салучы дип бик дөрес санала. Физика, химия өлкәсендә һәм табигать турындагы башка фәннәр өлкәсендә Ломоносовның даһиларча эзләнүләре асылда Россиядә тәҗрибәләр ясаучы табигать белеме чорын ачалар.

Ул үзенең фәнни эшләренең методын: „Күзәтүләрдән теорияне китереп чыгарырга, теория аркылы күзәтүләрне дөресләргә" дигән сүзләр белән билгеләде.

Ул беренчеләрнең берсе булып, матдәнең саклануы законын ачты. Ул атом - молекула теориясен тудыручыларның берсе булды, механик җылылык теориясен эшләде. Ул атмосферадагы электричествоның пар кисәкләренең бер-беренә ышкылуларыннан килеп чыгуын аңлатты.

XVIII нче йөзнең беренче яртысында әле химия сәнгать дип атала иде. Ломоносов аны фән дип атады һәм 1740 нчы елны ул химияне математика белән бергә бәйләү мөмкин дигән карашка килде.

Ломоносов Россиядә беренче буларак химия лабораториясе оештырды һәм руслардан беренче булып Фәннәр Академиясендә профессор исеме алды.

Ул бик күп кенә механик аппаратлар, оста итеп эшләнгән инструментлар һәм машиналар уйлап тапты.

Ул караңгы төшкәч әйберләрне ачык итеп күрү өчен „төнлә карый торган" труба һәм су астында карау өчен труба уйлап тапты, җилнең көчен билгеләү приборы—анемометр, һаваның югаргы катлауларындагы температураны үлчәү машинасын ясады. Ул телескопны яхшырту өстендә эшләде.

Ломоносовның сәләтләре гаять дәрәҗәдә күп яклы иде.

Россиядә онтылган сәнгать булган мозаиканы яңадан тудырып, ул үзе эшләгән күп кенә мозаик портретлар һәм „Полтава сугышы" исемле гаять зур „полотно" калдырды.

Минералогия һәм биология өлкәсендә дә Ломоносов күп кенә гүзәл фикерләр әйтте.

1742—1743 нче елларда ул „Металлургиянең беренче нигезләре" дигән китабын бастырырга хәзерләде.

1757 нче елны—Лиссабонда булган җир тетрәүдән соң озак та үтми—Ломоносов „җир тетрәгәндә металларның тууы турында" речь сөйләде. Ломоносовның бу речендә, беренче тапкыр, җир өстенең дулкынсыман селкенүе типы, шулай ук вулканнарның килеп чыгуына яңа караш бирелде.

Ул торфның, ташкүмернең һәм нефтьнең үсемлектән ясалганлыгын исбат итте, ташкүмернең җир астындагы ут катнашы белән торф сазлыкларыннан килеп чыкканлыгын исбат итте.

XVIII нче йөздә Россиядә тау промышленносте бары тик Урал, Олонец, Алтай һәм Нерченск таулары белән генә диярлек чикләнә иде. Ләкин Ломоносов Россиянең башка өлешләрендә дә тимер минераллар бик күп икәнлеккә ышанды һәм шул турыда сенатка язды.

Төньяк байлыкларын халыкка хезмәткә кую өчен күп көч биргән, онтылмаслык С. М. Киров үзенең речьләреннән берсендә Ломоносовның бөек хезмәтләрен искә алды. Сергей Миронович болай диде:

„Заманында Ломоносов та төньякта ниләр эшләнүне карау өчен шунда чакырган. Моннан 200 ел элек яшәгән бу үткен акыллы кеше түбәндәге сүзләрне әйтеп кайгысын белдергән: „Күп кенә дәлилләргә карап мин төньяктагы җирләрдә дә гаять күп һәм бай табигать бар дип һәм бу хәзинәләрне эзләрлек кеше юк дип нәтиҗә ясыйм!"

Ләкин Ломоносов җир асты байлыклары белән генә кызыксынып калмаган. Ул бөтенләй башка өлкәдә дә—рус теле өлкәсендә дә байлыклар ачты.

Ул чагында рус грамматикасы әле урта гасырлар характерында иде. Рус теле борынгы рус, чиркәү-славян һәм чит ил телләре сүзләреннән ясалган бер кушымта иде. Орфография кагыйдәләре юк иде, җөмлә төзелешендә бөтенләй башбаштаклык хөкем сөрә иде. Ломоносов рус грамматикасын тудырды һәм рус әдәби теле теориясенә нигез салды.

Үзенең беренче шигырьләреннән берсен—рус гаскәрләренең Төркиянең Хотин шәһәрен алулары уңае белән булган шигырен ул ямб белән—шуннан соң 100 ел чамасы үткәч Пушкин үзенең „Евгений Онегинын" язган үлчәү белән язды.

Ломоносов үләр алдыннан: „Мин үземне рус фәннәренең дошманнарына каршы үлгәнче көрәшүгә багышладым" диде. Ә „фән дошманнары" бөек галимне атлаган саен сагалап тордылар.

Ломоносов рәхимсез феодализм — крепостнойлык режимы шартларында, бөтен Россиядә меңнәрчә ерткыч крепостниклар котырынып йөргәндә яшәде, үзенең идеяләре өчен көрәште һәм иҗад итте.

Күп кенә мәсьәләләр буенча үз халкының интересларын яклап чыгып, Ломоносов шуның белән үзенең ул чагындагы рус җәмгыятендә булган реакцион элементларга каршы чыкканлыгын аңлады. Ул халыкны культурасызлыкта, юкбарларга ышанууда тотучы руханиларны аеруча кискен тәнкыйть итте. Попларны ул наданнар, палачлар дип атады.

Хөкем сөрүче дворяннар һәм руханилар бөтен алдынгылыкны буып килделәр. Алдынгы галимнәр эзәрлекләнделәр.

Ломоносовның шәкерте, профессор Клейнфельд үз-үзен үтерде. Ломоносовның иптәшләреннән берсе, рус фарфорын уйлап тапкан Виноградов чылбырга бәйләнде һәм акылыннан шашуга кадәр китереп җиткерелде, Ломоносовның икенче иптәше, Камчатканы талантлы тикшерүче Крашенинников бик мохтаҗлыкта яшәде һәм шундый ук мохтаҗлыкта билгесез булып үлде.

Ломоносов үзе дә соңгы көннәрендә күп авырлыклар күрде: аны һәр төрле юллар белән Фәннәр Академиясеннән читләтергә омтылдылар. Ләкин ул: „Мине Академиядән читләтеп булмас, Академияне миннән читләтсәгез читләтерсез" диде.

Ломоносовның Академия университетын үзгәртүгә юнәлдерелгән тырышлыгы һәм хезмәте дә искиткеч. Моның аркасында аңа берничә тапкырлар императрицага барып баш иярга туры килде.

Ломоносов крестьян балаларын университетка алуны тыюга каршы баш күтәрде, ә академикларның берсе „яхшы нәселдән" булган укучыларны „түбән" дәрәҗәле укучылардан аерырга тәкъдим иткәч Ломоносов үзенең протестын протоколга кертүне таләп итеп утырыш залын ташлап чыкты.

Ломоносов хезмәтләренең, яңалыкларының, планнарының,—башланганнарының һәм тәгәлләнмәгәннәренең исемлеге бик зур. Аның: „Минем башым күпне башлый, ләкин кулларым икәү генә" дип зарлануы бик аңлаешлы.

„Бөек һәм гүзәл булганнарны һәр кайда да сәгать саен тикшерегез" дигән васыять калдырган, рус университетларыннан „күп санлы Ломоносовлар чыгачак" заман турында хыялланган, үз халкының куәтле иҗад көчләренә, үз иленең бөек киләчәгенә тирәнтен ышанган бу кешенең образы безгә кадерле.

Ул үз ватанының бөек патриоты иде, үз халкын яратты һәм бөтен аңлы тормышы буена аның экономик һәм культура үсеше өчен көрәште.

Бөек рус галименең—энциклопедистның үлүенә 175 ел үтте, ләкин хәзердә дә әле Ломоносовның күп кенә идеяләре үзләренең әһәмиятләрен югалтмадылар. Марксизм-ленинизмга нигез салучылар безне, коммунизмны уңышлы төзү өчен үткәндәге фәннең казанышларын тәнкыйть ягыннан карап үзләштерергә кирәк дип өйрәтәләр. Ломоносовның—фән корифееның хезмәтләре культураның үткәндәге иң яхшы казанышлары рәтенә керәләр.

Г. Шторм.

М. В. Ломоносов.

Чит илләрдә

НОРВЕГИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

НЬЮ-ЙОРК, 13 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Германиянең бер линкоры, 3 эсминецы һәм күп кенә башка төрле кечрәк кораблары сугыштан соң булса кирәк Ослога килгәннәр. Кораблар янына санитария автомобильләре җибәрелгән. Англия радиостанциясе Стокһольмнан Норвегия верховный командованиесенең түбәндәге белдерүен алган: „Немецләр Ословы һәм аның бистәләрен алганнар. Норвегия гаскәрләре Ослодан төньякта һәм төньяк-көнчыгышта урнаштылар. Немецләр Кристиансундта, Ставангерда, Бергенда, Тронгеймда һәм Норвегиянең көньяк өлешендәге тагын ике яр буе пунктында контрольлек итәләр. Көньяк Норвегиянең калган өлеше норвегиялеләр кулында. Немецләр Нарвикны, э норвегиялеләр—Нарвиктан төньяктарак булган бөтен территорияне кулларында тоталар“.

Агентлыкның хәбәр итүенә караганда, Норвегия гаскәрләре барлык күперләрне һәм көньякка таба бара торган тимер юлларны шартлатканнар. Аларның гаскәрләре Скарнес районында тупланган.

Шул ук вакытта агентлык Осло-Фиордтан 27 миль көньяк-көнчыгыштарак һәм Ослодан төньяк-көнчыгыштарак Аским районында немец гаскәрләре белән Норвегия гаскәрләре арасында сугыш баруы хәбәр итә. Германиянең механикалаштырылган частьләре 15 артиллерия орудиесе белән берлектә Фетзундка таба хәрәкәт итәләр.

„Нью-Йорк таймс“ газетасының Норвегия—Швециянең төньяк чигендәге хәбәрчесе немецләрнең чиктән 4 миль ераклыкта Нарвиктан Хундаленга кадәр булган тимер юлны контрольлек итүләрен хәбәр итә.

Швециянең „Нюа Даглигт аллеханда“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Англия Тронгеймнан 12 миль төньяктарак, Фолден фиордында һава һәм диңгез көчләре туплаган.

Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Норвегия радиостанциясе Германиянең 7 сугыш карабының Осло бухтасында, 5 карабының һәм шул исәптән бер линкорының Тронгейм районында икенләнеп тапшырган. Хәбәр итүләренә караганда мондаАнглиянең һава һәм диңгез көчләре атака алып баралар. Англиянең ике эсминецы Фолден фиордына керү юлында тора. Шулай ук норвегиялеләрнең Ослодан көнчыгыштарак һәм төньяк-көнчыгыштарак булган автомобиль юлларына блокада ясаганлыкларын һәм шәһәрне чолгап алырга маташуларын хәбәр итәләр.

БЕРЛИН, 13 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Нарвик районында хәрәкәт итүче Германия гаскәрләре Нарвиктан Швеция чигенә таба бара торган юлларның күп өлешен алганнар.

БЕРЛИН, 13 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләре Кристиансундтан хәрәкәт итеп, Хегеланд шәһәренә барып җиткәннәр. Норвегия гаскәрләре һич бер төрле каршылык күрсәтмәгәннәр.

БЕРЛИН, 13 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Тронгейм белән Швеция арасында тимер юл хәрәкәте ике юнәлештә дә нормаль төстә бара.

НЬЮ-ЙОРК, 13 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Стокһольмнан алып хәбәр итүенә караганда, Норвегия армиясе штабы игълан иткән белдерүдә Осло-Фиордта Германиянең „Гнейзенау“ линкорының, „Эмден“ крейсерының һәм берничә вак карабының батырылганлыгы хәбәр ителә. Шулай ук Норвегиянең дә берничә сугыш карабы батырылган. Анна-ра белдерүдә Норвегия оборона линиясенең Нисен, Гломма елгасы, Эйерен, Ромерике, Хитедал, Тюри фиорды һәм Виксенд аркылы үтүе күрсәтелә.

ЛОНДОН, 13 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Париждагы хәбәрчесенең хәбәр итүенә караганда, алынган мәгълүматлар буенча Франция флотының 20 ләп сугыш карабы Норвегия ярлары буендагы операцияләрдә Англия флоты белән берлектә хәрәкәт итәләр.

ЛОНДОН, 13 апрель. (ТАСС). Англия диңгез министрлеге Норвегиядәге сугыш хәрәкәтләре турында түбәндәге белдерүне таратты: „Норвегия суларында Англия флотының дошманга каршы операцияләре дәвам итә. Кичә Англиянең һәрби диңгез һәм һәрби һава көчләре дошманның Бергендагы сугыш карабларын, транспортларын һәм сугыш кирәк-яраклары төялгән карабларны бомбага тоттылар. Сугыш складлы юкка чыгарылды һәм торпеда катерына пулеметтан атылды. Һава шартлары бик начар иде, шуның нәтиҗәсендә безнең самолетларның берсе диңгезгә төшәргә мәҗбүр булды. Калган самолетлар үз базаларына кайттылар“.

ЛОНДОН, 13 апрель. (ТАСС). Англия авиации министрлегенең хәбәр итүенә караганда, кичә Англия бомбардировщикларының зур берләшмәләре Германиянең үз базасына кайтучы флотын бомбага тоту теләге белән Норвегиянең һәм Даниянең территориаль сулары районында разведка очышлары ясаганнар. Бомбардировщикларның бер берләшмәсе Кристиансунд фиордына керәп, анда Германиянең сугыш карабларына бомба ташлаган. Дошман Англия самолетларына каршы көчле ут ачкан. Англия бомбардировщикларының төньякка, Ставангерга таба юнәлгән икенче берләшмәсе юлда дошманның күп сандагы истребительләренә очраган.

Министрлекнең белдерүендә хәбәр ителүенә караганда, авиациянең аеруча җанлы сугыш хәрәкәтләре вактында Англия самолетлары Германиянең „Мессершмитт“ типындагы 4 истребителен бәреп төшергәннәр. Болардан тыш Германиянең тагын 2 самолеты бәреп төшерелгәндер һәм берничә самолетына зыян китергәндер дип уйлыйлар. Шул ук вакыт эчендә Англия 8 самолетын югалткан. 2 самолет үз базаларына кайткан вакытта юлда һәлак булган.

Германия армиясе верховный командованиесенең сводкасы

БЕРЛИН, 13 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге сводканы игълан итте: „12 нче апрельдә Германиянең Норвегиядәге гаскәрләре күздә тотылганча ярдәм алдылар һәм шуның аркасында гомуми хәл яхшырды. Германиянең Нарвик районындагы гаскәрләре элеккечә сугыш ягыннан әһәмиятле пунктларны ныгытуда эшләделәр. Англия тарафыннан десант төшерергә маташу булмады. 12 нче апрельдә Нарвик портына һавадан һөҗүм ясау уңышсыз чыкты. Шул ук вакытта Англиянең бер самолеты бәреп төшерелде. Тронгейм районында элеккечә тыныч. Яр буе оборонасын ныгыту уңышлы барды. 12 нче апрельдә кич белән англичаннарның көчле һава берләшмәләре Бергенга һөҗүм ясарга маташтылар, ләкин Германия авиациясенең вактында хәрәкәт итүе аркасында кире кагылдылар. Берген санитар карабында, дошманның 8 самолеты бәреп төшерелгән, шуның белән бергә самолетларның берсен зенит артиллериясе бәреп төшергән. Германиянең ике самолеты үз базасына кайтмады. Төнлә Ставангерга ясалган һава һөҗүме дә уңышсыз чыккан. Дошманның бер самолеты бәреп төшерелде. Осло районында көне буена берничи әһәмиятле сугыш хәрәкәтләре булмады. Кичә диңгездә зур сугыш хәрәкәтләре булмады“.

НОРВЕГИЯДӘГЕ ХӘЛ

СТОКҺОЛЬМ, 13 апрель. (ТАСС). Инде хәбәр ителгәнчә, Норвегия гаскәрләренең бер өлеше Германия армиясенә каршылык күрсәтүне дәвам иттерә. Норвегия чигеннән хәбәр итүләренә караганда, Ослодан көнчыгышка һәм төньяк-көнчыгышка бара торган барлык юллар ябылган. Хәзер Норвегиялеләр Осло тирәсендә бөкржаны кысарга маташалар. Норвегия гаскәрләре Осло-Фиордта Мосстан алып Халден, Консвингер, Эльверум аркылы Гьервикка кадәр ярым бөкржа булып торалар. „Афтонбладет“ хәбәрчесенең Консвингердан телеграф буенча хәбәр итүенә караганда, Скарнес белән Эйдсволд һәм Вормзунд арасында 11 нче апрельдән бирле каты сугышлар бара. Консвингердән Норвегия гаскәрләренә ярдәмгә җиңел автомобильләрдә һәм автобусларда гаскәрләр җибәрелгән. Консвингер халкы күчерелә. Эльверумны икенче тапкыр бомбага тоткан һәм соң шәһәрдә янгын башланган. Фредрикстад юлы качаклар белән тулган. Норвегия чигеннән хәбәр итүләренә караганда, Германия авиациясе отрядлары Норвегиянең чик буе районнары өстендә очканнар.

Стремстадтан (Норвегия чигендә Швеция шәһәре) хәбәр итүләренә караганда, кичә диңгездә төн бик тынычсыз булган. Төн уртасында шәһәргә көчле ату тавышы ишетелеп торган һәм көнбатышта һава яктылык бомбаларының һәм прожекторлардан бик нык яктылы булып торган. Анда диңгездә зур сугыш булгандыр дип уйлыйлар. Кичә иртә белән Стремстадка якын гына урында Германия транспорты торпедага бәрелгән һәм каты шартлаудан соң баткан.

„Нюа Даглигт аллеханда“ газетасы җәя Норвегия чигеннән хәбәр итүенә караганда, Англиянең составында ике линкор, 4 крейсер һәм 4 истребитель булган зур һәрби диңгез көчләре Тронгеймнан чама белән 15 миль төньяктарак Намсос Фиордында тупланган. Бу районда диңгез сугышы булыр дип көтәләр.

НОРВЕГИЯНЕҢ ДИҢГЕЗ ОФИЦЕРЛАРЫНА МӨРАҖӘГАТ

ОСЛО, 13 апрель. (ТАСС). Норвегия телеграф агентлыгы Норвегиянең диңгез офицерларына Норвегиягә кайтырга чакырып мөрәҗәгать игълан итә, чөнки көрәшне дәвам иттерү нәтиҗәсез. Диңгез караблары сугыш хәрәкәтләрен туктатырга тиешләр.

Германиянең Норвегиядәге гаскәрләренә ярдәм китерү

ЛОНДОН, 13 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының радио буенча хәбәр итүенә караганда, бүген Лондонга алынган хәбәр буенча хәзер Германиянең Норвегиядәге гаскәрләренә һава юлы буенча ярдәм китерелә. Гаскәрләр самолетларга төяләп Даниядән җибәреләләр. Норвегиянең Лондондагы илчесе бу мәсьәлә буенча Галифакс белән киңәшкән.

Агентлыкның сүзләренә караганда, Ньюгордсволд кулында бары 2 генә радиостанция бар икән. Аларның берсе Бодода, икенчесе—Тромсода. Англия радиостанциясе хәзер алар белән элемтә тоталар.

13 нче апрельдә Казанда балаларның художество үзешчәнлеге көчләренә смотр үткәрелде. Рәсемдә (сулдан уңга): 41 нче мәктәпнең 1 нче класс укучысы Юра Яковлев (скрипка), шул ук мәктәпнең 1 нче класс укучысы Лиля Бейрах (декламация) һәм Казан тимер юлының 1 нче номерлы мәктәбе (10 нчы класс) укучысы Асия Шәехова (бию). И. Галиев фотосы.

ЯШ ТАЛАНТЛАР

13 нче апрельдә Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында балаларның үзешчәнлек сәнгате көчләренә шәһәр күләмендә смотр үткәрелде.

Сәхнәдә шәһәр мәктәпләреннән җыелган пионерларның 400 баланы эченә алган хоры. Хорга Татарстанның атказанган артисткасы Зөләйха иптәш Әхметова җитәкчелек итә. Залда „Сталин турында җыр“ яңгырады. Аннан соң пионерлар йортының җыр һәм бию ансамбленең чыгышлары булды.

Смотр программасына совет композиторларының, совет язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләре, җыр, бию номерлары һәм башкалар кертелгән. Декламаторлардан Гера Рыкачова һәм Виля Шлейфман үзләренең номерларын бик яхшы итеп башкардылар. Яш җырчы Коля Рыбаков хорга кушылып „Пионерлар хиялы“н үзенең матур тавышы белән сокланырлык итеп оста башкарды. Смотр кичәсендә шулай ук халык җырлары, биюләре һәм башка номерлар үтәлде. Татар һәм рус халык биюләре, украинча гопак һәм башка номерлар залда утыручылар тарафыннан аеруча кайнар рәвештә каршыландылар. Кичәнең икенче өлешендә аерым номерлар башкарылды. 91 нче номерлы мәктәп укучысы Вова Истомин Чуковскийның „Телефон“ шигырен һәм башкаларны бик зур осталык белән сөйләде. Асия Шәехова үзбәк биюен, М. Шаһиева һәм Лиля Бейрах үзләренең декламацияләрен гаять оста башкардылар.

Балаларның үзешчәнлек сәнгате смотры балалардагы иҗад байлыгын, яш талантлардагы иҗад күтәренкелеген тагын бер тапкыр күрсәтте. Смотр кичәсендә шәһәр мәктәпләренең укучылары, педагоглар, ата-аналар, партия, совет һәм җәмагать оешмаларының вәкилләре катнашты.

Осоавиахимның 14 нче лотереясе

15 нче апрельдә Осоавиахимның 14 нче лотереясе билетларын урнаштыру башлана.

Татарстанга 1 миллион 600 мең сумлык лотерея билетлары алынды һәм районнарга җибәрелде.

Лотерея буенча барлыгы 25 миллион сумлык 410.500 отыш уйналачак. Отышлар арасында 27 шәр мең сумлык 4 данә „ЗИС“ маркалы автомобильләр, 18 данә „М—1“ маркалы автомобильләр, 75 данә мотоцикл, 49 пианино, 372 велосипед һәм башкалар бар.

Осоавиахимның Татарстан Үзәк Советы лотерея билетларын урнаштыруны 15 нче майга төгәлләү турында йөкләмә алды һәм Осоавиахимның Башкыртстан Үзәк Советын ярышка чакырды. Осоавиахимның Башкыртстан Үзәк Советы бу чакыруны кабул итте. Лотерея билетларын урнаштыруда булышлык күрсәтү өчен Татарстан районнарына Осоавиахим активыннан 21 кеше җибәрелде.

* * *

Осоавиахимның Молотов район советы Осоавиахимның 14 нче лотереясе билетларын урнаштыру эшенә керешә.

Районның барлык предприятиеләре, учреждениеләре һәм уку йортлары лотерея билетларын күпләп алалар.

Осоавиахим лотереясе билетларына беренче взнос

ЮТАЗЫ. (Телеграф буенча). Шушы көннәрдә Ютазы авыл советына караган колхозлардагы колхозчыларның җыелышы булды. Алар СССР ның тышкы политикасы турында иптәш Молотовның докладын өйрәнделәр һәм Совет хөкүмәтенең тышкы политикасын бердәм рәвештә яхшы дип таптылар. Җыелышта 500 гә якын кеше катнашты. Колхозчылар Осоавиахим эшен тагын да җанландыру турында конкрет карар кабул иттеләр. Осоавиахимның 14 нче лотереясе билетларын алу өчен 1.650 сум взнос керттеләр.

Әхмәдиев.

Колхоз кырларына агач утырту

Игенлекләрне корылыктан саклау өчен колхоз кырларында урман полосалары ясау эшләре үткәрелә. Быел яз көне Татарстан колхозларында 1.400 гектар мәйданга агач утыртылачак. Шуның өстенә чокырларны һәм комлыкларны ныгыту өчен 300 гектар мәйданда әрәмәлекләр ясала. Колхоз кырларына юкә, имән, нарат, чыршы, өрәңге агачлары, чокырларга һәм комлыкларга акация, гөлҗимеш, карга миләше, зелпе, алма һәм чия агачлары утыртылачак. Аларга утырту өчен питомниклардан 16 миллион төп төрле агачлар җибәрелә.

Бәйрәм алды сәүдәсенә хәзерлек

Татнаркомторг һәм Казандагы сәүдә оешмалары Беренче Май бәйрәме алды сәүдәсенә зур хәзерлек эшләре алып баралар.

Бәйрәм алды сәүдәсе өчен 150 тоннадан артыграк шикәр, 75 тонна халва, 150 тонна кондитер әйберләре, павидло, балык, селедка, консервы һәм күп санда яшелчә продуктлары хәзерләнде дә инде. Шушы көннәрдә 3 вагон кесәл, 2 вагон фрукты, 6 вагон эчемлек товарлары килүе көтелә. Продукт товарлары белән сәүдә итүче, магазиннарда сәүдә вакты 25 нче апрельдән башлап 2 сәгаткә озынайтылачак.

25 нче апрельдә Казандагы колхоз базарларында бәйрәм алды базарлары ачыла. Бу базарларда Казанга якын районнарның күп колхозларыннан авыл хуҗалыгы продуктлары китереләчәк. Хәзер Казандагы сәүдә оешмалары бәйрәм алды базарларында сату өчен промышленность товарлары хәзерләү эшенә керештеләр.

* * *

Зеленодольски, Чистай шәһәрләрендә һәм башка район үзәкләрендә дә 25 нче апрельдән 30 нчы апрельгә кадәр бәйрәм алды базарлары үткәрелә. Бу эшне оештыру өчен Татнаркомторг һәм Татсовнарком тарафыннан урыннарга аерым кешеләр җибәрелде.

Укытучыларга ссудалар

Татарстан авылларындагы мәктәпләрдә укытучыларга индивидуаль йортлар салу өчен быел Авыл Хуҗалыгы банкысыннан 145 мең сум кредит бирергә билгеләнде. Индивидуаль йорт салырга теләүче һәрбер укытучыга 4 мең сумга кадәр ссуда алырга мөмкин. Ссуда 5 ел срокка бирелә.

ВЕТЕРИНАРИЯ БОЛЬНИЦАЛАРЫ

Узган ел Татарстанда ветеринария больницалары һәм амбулаторияләре төзелешенә Госстрахтан 2 миллион 100 мең сум акча бирелгән иде. Бу акчага 7 урында врач амбулаторияләре, 27 урында фельдшер амбулаторияләре, 14 изолятор, 9 больница һәм башка бинолар салына. Быел бу төзелешләрне тәмам итү, шулай ук яна больницалар һәм амбулаторияләр төзү өчен Госстрахтан 2 миллион 400 мең сум акча бирелә.

ЕЛГАЛАРДА

Волга суы 14 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Ржевтан алып Горькийга кадәр 10—32 сантиметр артты. Волганың югары ягында боз ага башлаганы юк әле. Горький янында 24 сантиметр, Козьмодемьянски янында 39 сантиметр, Кама Тамагы янында 10 сантиметр су артты. Казан яны боздан арчылды. Тәтештән алып Сталинградка кадәр көчле рәвештә боз ага.

Кама суы Молотов шәһәре янында 37 сантиметр, Сарапуль янында 34 сантиметр, Лаеш янында 10 сантиметр артты. Красный Бордан алып Лаешка кадәр боз ага.

Агыйдел бозы агып бетте.

Вятка елгасында Вятские Поляны һәм Мамадыш янында боз ага башлады.

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты элек Житен комбинатында эшләгән Саимә Шакир кызы Шакированың ВКП(б) ның Шәһәр Комитетына 18 нче бүлмәгә килүен сорый.

Иптәш Шакированың тору яисә эшләү урнын белүчеләрдән, ул турыда Шәһәр Комитетына белдерүләре сорала.

ВКП(б) ШК ның оештыру-инструкторлык бүлеге.

Республика олимпиадасына хәзерлек

Татарстан АССР ның XX еллыгы бәйрәменә туры китерелеп май ае ахрында, Казанда, республика күләмендә халык иҗады олимпиадасы үткәрелә.

Күп кенә районнарның җитәкчеләре, комсомол, профсоюз оешмалары, клублар, түгәрәкләр олимпиада белән бик нык кызыксынганлыкларын күрсәттеләр. Красный Бор, Куйбышев, Әгерҗе, Буденный, Тымытык, Азнакай, Алабуга, Арча, Буа районнарында район олимпиадасын үткәрү комиссияләре нык лап эшкә керештеләр. Бу районнар колхоз, совхоз, МТС ларда һәм башка урыннарда район олимпиадасына катнашырга лаеклы үзешчән сәнгать көчләрен сайлап алу кичәләрен һәм район олимпиадаларын үткәрделәр, республика олимпиадасына катнашу өчен кандидатлар билгеләделәр. Олимпиада зур күтәренкелек белән үтте.

Әгерҗе районында олимпиада 2 көн булып, анарга 286 кеше катнашты һәм аны 2 меңнән артык кеше карады. Буденный районында 57, Красный Бор районында 182, Буада 134 кеше олимпиадага катнашты.

Күрсәтелгән районнарның барсында да дип әйтерлек район олимпиадасында өстен чыгучылар бүләкләнделәр. Азнакай районында иптәш Хәсәнова җыр белән беренче урынны алды һәм 200 сум акча белән бүләкләнде. Ибраһимов төрле гармоннарда уйнауда, Хәйруллин биюдә, Лотфуллина җырлауда алдынгылык күрсәтеп 100 әр сум белән бүләкләнделәр.

Республика олимпиадасына катнашу өчен Әгерҗе район комиссиясе 32 кешене, Буденный—7, Красный Бор—30, Алабуга—20, Тымытык район комиссиясе 2 кеше билгеләделәр.

Республика олимпиадасына катнашырга билгеләнгән түгәрәкләрнең репертуарлары бик төрле һәм күңелле булуы көтелә. Алабуга драмтүгәрәге Островскийның „Урман“ исемле пьесасын, Әгерҗе драмтүгәрәге Р. Ишмуратның „Ил өчен“ исемле пьесасын күрсәтәчәкләр. Алабугадан иптәш Камишкерцова Л. Толстойның „Воскресенье“ исемле романыннан өземтәләр укыячак. Тымытыктан Гариф иптәш Солтанов үзе уйлап тапкан машинасын күрсәтәчәк. Азнакай районыннан Хәсәнова һәм Лотфуллина иптәшләр җыр белән, Ибраһимов төрле гармоннар белән, Хәйруллин бию белән, Килмәкәев нәфис сүз белән катнашачаклар. Буденный районыннан 4 кеше бию белән, берәр кеше җыр һәм уен кораллары белән киләчәкләр. Красный Бор районыннан 5 кешедән торган Бикмурзиннар семьясе, 4 кешедән торган Кожухлар семьясе, апалы-энеле укытучы Мостафиннар, НКВД работниклары хатыннарыннан торган 15 кешелек хор, төрле уен кораллары, җыр, бию һ. б. белән катнашачаклар.

Казандагы клубларның да күбесе шәһәр һәм республика олимпиадасына катнашу өчен нык лы хәзерлек алып баралар. Сукырлар җәмгыяте клубы Г. Камалның „Беренче театр“ ын, тынлы оркестр, татар һәм рус хорларын хәзерли. Бу оешмадан шәһәр олимпиадасына 52 кеше катнашачак. Менжинский исемендәге клуб тынлы оркестр, Орджоникидзе исемендәге заводның татар драмтүгәрәге Островскийның „Дөреслек яхшы, бәхет яхшырак“ исемле пьесалары белән, 80 кешедән торган ансамбль тарафыннан куелачак „Колхоз яшьләре ялда“ дигән темадагы монтаж белән катнашачаклар. Ленин исемендәге заводның татар драм түгәрәге „Хан кызы Турандот“, рус драм түгәрәге „Тартюф“ исемле пьесаларны куячаклар, хор, оркестр, бию коллективлары, рус, татар композиторларының әсәрләрен үтәячәкләр. Медицина работниклары йорты олимпиадага Фәтхуллинның „Күзләр“ ен, М. Горькийның “Соңгылар“ын, Чайковскийның „Евгений Онегин“ операсын һәм концерт номерлары хәзерли. Укытучылар йорты коллективы, Дәүләт университеты, мехчылар, Жиркомбинат, киез итек фабрикасы, дәүләт сәүдә клубы түгәрәкләре һәм башка клублар да олимпиадага катнашырга хәзерлек алып баралар.

Ләкин шуның белән бергә, республика олимпиадасына хәзерлектә булган кимчелекләрне дә күрсәтми китеп булмый. Республика хөкүмәт комиссиясендә Аксубай, Актаныш, Апас, Бондюг, Зур Тархан, Ворошилов, Мамадыш, Чаллы, Шөгер, Питрәч, Норлат, Саба, Кама Тамагы һәм башка районнар буенча олимпиадага хәзерлекнең ничек баруы турында материаллар юк, олимпиада үткәрү өчен комиссия төзелгәнме, юкмы, билгесез. Кукмара, Баулы районнарында олимпиада үткәрү өчен билгеләнгән комиссияләр бер нәрсә дә эшләмәгәннәр.

Әлмәт район комиссиясе (председателе ВКП(б) райкомының агитация-пропаганда бүлеге мөдире иптәш Шакиров), Октябрь (председателе район парткабинет мөдире иптәш Николаев), Ютазы (председателе ВКП(б) райкомының агитация-пропаганда бүлеге мөдире Афзалов), Чүпрәле (председателе район советыннан Крайнов), Минзәлә (председателе Минзәлә театры мөдире Амутбаев) һәм башка районнарда комиссияләрнең ничек эшләүләре турында шулай ук бер нинди дә хәбәр юк.

Республика олимпиадасына бары ай ярым вакыт калды. 1 нче майга кадәр, Татарстанның барлык районнарында район олимпиадалары үткәрелеп бетәргә һәм республика олимпиадасына катнашучылар сайлап алынган булырга тиеш.

Казан шәһәр клублары апрель аеның ахрында үткәреләчәк шәһәр олимпиадасына нык лы хәзерлек алып барырга тиешләр.

Республика күләмендә үткәрелә торган үзешчән сәнгать олимпиадасы зур политик әһәмияткә ия булып тора. Аңа лаеклы кандидатлар билгеләп, аларның бу олимпиадада өстен чыгуларына ирешү—партия, профсоюз, комсомол, җәмагать оешмаларының һәм түгәрәк җитәкчеләренең, түгәрәк членнарының сугышчан бурычлары.

И. Юзиев.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

„Трансэнергокадр“ ның Казан бүлеге шушы ел 20 нче апрельдән производстводан аерып укытып кочегарлар һәм машинистлар хәзерләү буенча

КУРСЛАР АЧА

Кочегарлар хәзерләү курсларында уку срогы 2 ай. Уку расходлары өчен түләү—271 сум.

Пар машиналарына, локомобильләргә һәм эчке янулы двигательләргә хезмәт күрсәтү өчен машинистлар хәзерләү курсларында уку срогы 3 ай. Укыту расходлары өчен түләү—408 сум.

Курсларга предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алына. 607—2—1

Казан Дәүләт Мединституты Акушерка-Гинекология клиникасының оваль формадагы урлангaн печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 574—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Бүген, 15 нче апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында, Татарстан АССР ның атказанган артисткасы

МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВА

КОНЦЕРТЫ

Кич 9 сәгатьтә башлана.

16 нчы апрельдә ИРЕК

19 нчы апрельдә Зур театр бинасында ФАУСТ

Кич 8 сәгатьтә башлана.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

15 һәм 16 нчы апрельдә

КУРКЫНЫЧЛЫ СУД

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры

17 нче апрельдә КЫЮ КЫЗЛАР

18 нче апрельдә көндез һәм кич ТАНЯ

Талоннар белән кертелми.

Спектакль кич 8 сәгатьтә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә

ЗУР ЦИРК УЕНЫ

ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ ЯРЫШЫ

ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ДУСЛАР ЯҢАДАН ОЧРАШАЛАР
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ЯҢА ЗАМАННАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ

КИРӘК:

АПТЕКАЛАР ҮЗӘК СКЛАДЫНА АШЫГЫЧ РӘВЕШТӘ БАШ БУХГАЛТЕР, ПЛАНОВИК һәм вакытлы эш өчен МАШИНИСТКА. Тәкъдимнәр белән килү өчен адрес: Казан, Астрономия урамы, 15, склад конторасы. 613—1

Даими эшкә ашыгыч рәвештә, БАШ БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ, (трест буенча эшләү өчен), ФИНАНС СЕКТОРЫ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР, АШХАНӘЛӘР ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОР, РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ БУХГАЛТЕРЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР, БӘЯЛӘР БУЕНЧА ЭКОНОМИСТ-ПЛАНОВИК, СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, АЗЫК ТОВАРЛАРЫ БУЕНЧА ТОВАР БЕЛГЕЧЕ һәм БОНДАРЛЫК ПРОИЗВОДСТВОСЫ ӨЧЕН МӨДИР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Киров районы, Ашханәләр тресты, кадрлар секторы. 616—1

Росглавхлеб Татарстан трестының транспорт базасына даими эшкә РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ БУХГАЛТЕРЫ, РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ ХИСАПЧЫСЫ, ТАКСИРОВЩИК, ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР УРЫНБАСАРЫ, ТОКАРЬЛАР һәм СЛЕСАРЬЛАР. Казан, Колхоз урамы, 20. 609—2—1

Казан Эпидемиология һәм Микробиология институтына даими эшкә КАРТОТЕКАЧЫ, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАР һәм термос, шулай ук автоклав эшләрен белүче СЛЕСАРЬ. 575—3—3

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1384. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ №: 1439.